# Мөнәҗәтләр – жан авазы

1100-летие принятия Ислама Волжской Булгарией

МИНИСТЕРСТ
КУЛЬТУРЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

Тат
Культ
Ресурс
Центр

# Мөнәҗәтләр – җан авазы

УДК
ББК

Россиядә Идел буе Болгар дәүләтендә Ислам динен кабул итүгә 1100 ел тулу уңаеннан нәшер ителә.

**Проект авторлары:** А.Р. Мифтахова, ДБҮ «Таткультресурсүзәге» директоры; Г. М. Латыйпова, ДБҮ «Таткультресурсүзәге» директоры урынбасары, тарих фәннәре кандидаты; Р.М. Гайфетдинова ДБҮ «Таткультресурсүзәге»нең Тикшеренүләр һәм традицион мәдәниятне саклау бүлеге мөдире, фәлсәфә фәннәре кандидаты.
**Кереш мәкаләне язучы:** филология фәннәре докторы, профессор Т.Н. Галиуллин
**Җыентыкны төзүче, сүзлек һәм искәрмәләрне әзерләүче:** фәлсәфә фәннәре кандидаты Р.М. Гайфетдинова

Мөнәҗәтләр — җан авазы. — Казан, ИП «Мусабирова Р.М.», 2022. — 94 б.

Бу җыентыкка төрле жанрдагы, шул исәптән дини һәм фәлсәфи, яшәү һәм үлем, сабырлык, ана һәм бала турында мөнәҗәтләр тупланды. Мөнәҗәтләр 2022 елда ДБУ «Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә традицияләр һәм ииновацияләрне саклау ресурс үзәге» тарафыннан Әтнә, Буа, Казан, Аксубай, Саба муниципаль районнарына оештырылган фәнни-этнографик экспедицияләр вакытында язылып алынды.

**Дизайн, верстка, бизәлеш мөхәррире:** Р. М. Мусабирова.
**Техник мөхәррир:** Г. М. Латыйпова.
**Текстларны җыючылар:** Э.Р. Гайнетдинова, Р.Р. Мәһдиева, И.Ә.Кыямов.
**Аудио һәм видеоязмага төшерүче:** Р.М. Муртазин, АЧҖ «К-центр».

Татар халык иҗаты — тормыш-яшәешнең төрле кыйтгаларын сүз-сурәт белән тасвирлаган кыйммәтле рухи мирасыбыз. Маҗаралы вә тормышчан әкиятләр, мәгърур дастаннар, фаҗигале бәетләр, тапкыр мәкаль-әйтемнәр, кешенең сөенечле дә, сагышлы да хисләрен чагылдырган лирик, тарихи йола җырлары янәшәсендә, бары тик ислам динен тотучыларга гына хас, халык сүз сәнгате белән язма шигърият бердәмлеге җимеше — илаһи жанр — мөнәҗәтнең «йөрәге тибүе» дә мәгълүм.

Шактый күп санлы һәм төрле лөгатьле мәмләкәтләр даирәсендә киң таралган һәм халыкның «җан авазы» буларак кабул ителгән мөнәҗәтләр бер дә юктан гына барлыкка килеп, фольклорның түр башына «менеп» утырмадылар.



Мөнәҗәт — халык күңеленә, рухына ислам диненең кануннарын мәңге онытмаслык итеп сеңдерү көченә ия лирик жанр. Мәгълүм булганча, гарәпләрнең Мәккә, Мәдинә шәһәрләрендә кабул ителгән дин үзенең самими, савыктыргыч илаһи нурлы көче белән сибелеп, таркалып, әлегәчә потларга таянып яшәгән кабиләләрнең күңеленә хуш килә. Ислам тиз арада Гыйрак, Иран, Күвәйт, Төркия, Мавр Испаниясе, өлешчә Кытай, Һиндстан илләренә үтеп керә. Азак (Азов) диңгезе, Идел-Чулман елгалары тирәләрендә гомер иткән, иген иккән, балалар үстергән болгар бабаларыбыз әле Мөхәммәд пәйгамбәр исән-имин чакта ук исламга тартылалар. Дәүләти, хәрби, игътисадый, мәдәни яктан алдынгы империяләрнең берсе дәрәҗәсенә күтәрелгән Хәлифәт үз йогынтысын җиһанның төньягында озак

яшәгән халыкларга иңдерү турында кайгыртып, 922 елда Әхмәд ибн Фадлан җитәкчелегендәге илчелеген Урта Идел буена юнәлтә. Үзләре дә җылы якта яшәгән мәмләкәтләр, дәүләтләр белән аралашу юлларын эзләгән бабаларыбыз шул арадашчылар йогынтысында һәм күңелләре тартуы нәтиҗәсендә мәҗүси Тәңречелектән китеп, ике дини тәгълимат арасында эчке рухи якынлык күреп, ирекле рәвештә, ислам динен кабул итәләр. Канунннары ышандырырлык уйланылган яңа галәмгә (идеологиягә) табынуның күп сәбәпләреннән берсе — күпчелек инсанны куркытып торган үлемнән соң, диннең катгый таләпләр үтәгәннәрне мәңгелек җәннәтнең барлыгына ышандыру көченә ия булуы иде. Мөэмин-мөселманнар өчен Алла иң югары рухи таяныч һәм гадел хөкемдар буларак күзаллана. Авырлык килгәндә Аллаһы Тәгаләгә сыену, өлкәннәргә шәфкать, ата-ананы олылау, намуслы хезмәт, гарип-горабаларга, ярлыларга ярдәм итү кебек канунннарның инсафлы күңелләргә хуш килүе бәхәс тудырмый. Ике халәтне, ягъни үлем белән яшәүне капма-каршы куюю алымы белән оҗмахның асыл яклары, нигъмәтләре белән ымсындыруы кешеләрдә матур киләчәккә («теге дөньяда» булса да) өмет чаткылары уята. Җәннәтнең тарту көчләрен сурәтләүдә мөнәҗәтчеләр хыялларына тулы ирек бирәләр.

*Дөнья йорты фанидыр, фанидыр нигъмәтләре,*
*Бакый итеп безгә Аллаһ кыйлгандыр җәннәтләрне.*
*Җәннәт эчрә мөэмин колың, хөллә булыр туннары,*
*Ни теләсәң, шуңа әзер торыр хурлары.*
(«Җәннәт эче — хозур бакча»).

Ислам канунннарын халык күңеленә ирештерүдә бе-

ренче үрнәкләр хәзер Сүрия урнашкан җирлекләрдә туган көйле, моңлы мөнәҗәтләр һәм аларга якын өслүбтә иҗат ителгән шәрыкъ, бигрәк тә суфичыл мистик шигърият ярдәмгә килә. Үзәктә шул ук «ике дөньяны» янәшә кую галәме (идеологиясе) алга чыга.

*Игелек кыл! Иң нык күпер шул булыр ул!*
*Җәннәтеңә иткән тугры юл булыр ул!*
(Юныс Әмрә).

Ислам тәгълиматын кабул итү халкыбызның киләчәге өчен бәяләп бетергесез олы вакыйга була. Күренекле тарихчы Р. Әмирханов язганча: «…Ислам әхлагыбыз сагында гына түгел, милләтнең этник сафлыгы сагында да торды… Ислам, шәригать ата-бабаларыбызның гасырлар дәвамында яшәү рәвеше, Иманы булган»[1].

Ислам дине белән берүк вакытта диярлек таралган мөнәҗәт — дин белән Адәм балалары арасында арадашчы һәм элемтәче вазифаларын үти.

Аллаһның кодрәтенә, бөеклегенә, бердәнберлегенә инангач, дини кешеләрнең күңел серләре шигъри юлларга саркый башлый. Татар мохитендә дә мөнәҗәтләр Аллаһка табынган эчтәлекләре, көйле, моңлы сурәтлелек чаралары белән теләктәшлек табалар һәм яшәешебезнең төрле чорларында аның юанычы, рухи таянычы дәрәҗәсенә күтәреләләр. Казан ханлыгы буйсындырылгач, исламнан биздереп, көчләп чукындырулар чорында, 1917 елгы инкыйлабтан соң, аларда ислам дине белән бәйле хис алга сөрелә дип, мөнәҗәт-

[1] Әмирхан Р. Иманга тугрылык. — Казан: Тат. кит. нәшр., 1997. — Б. 138.

ләр мәгариф, фән игътибарыннан читкә тибәрелделәр. Халык нинди авыр, дәһшәтле изүләр заманында да үзенең рухи таянычыннан, сәнгати байлыгыннан баш тартмый, мөнәҗәтләр халык күңелендә һәм һәр төрле язма чыганакларда сакланып, иҗат ителә, тарала торалар.

Төп үзенчәлеге Аллага табыну, ярлыкау, киләчәген аңа тапшыру булган мөнәҗәтләрнең саклануына үз өлешләрен башкаручылар, мөнәҗәт әйтүчеләр дә кертәләр. Дини бәйрәм көннәрендә Миңгол Галиев, Җәмил Зәйнуллин, Зөһрә Сәхәбиева һ. б. башкаруында мөнәҗәтләрне ишетмәгән, илһамланып сокланмаган татар телле кеше юктыр.

Мөнәҗәтләрнең күбесен шагыйрьләр, шәкертләр, дин әһелләре иҗат итсә дә, еш кына үз исемнәрен куймаганнар, шуңа күрә алар халык теленә кереп, рухи мирасыбыз булып киткәннәр. Мөнәҗәт — фани дөнья белән «теге» дөньяны тоташтыручы космик жанр. Аның төп максаты — җирдәге тормышның, ыгы-зыгының, байлык, мал артыннан куының вакытлы булуын, ахыр чиктә барчабызның да Аллаһ хозурында икәнлегебезне күңелгә сеңдерү.

Кем булсаң да, нинди генә «югары кәнәфиләр биләсәң» дә, адәм баласы тормышының кыска булуын, мәңгелек турында вакытында уйлауның зарурлыгын, Алла кулында икәнлегебезне бер мизгелгә дә онытмаска чакыруы, искә төшереп торуы белән үзенчәлекле. Мөнәҗәтләр тарихы белән кызыксыну шуны күрсәтә, бу борынгы жанр «бабайлар» истәлеге дип уйлаучылар бик нык ялгышалар икән. Шагыйрә Флера Тарханова бакыйлыкка күчүе алдыннан «Рамазан»

мөнәҗәтен язып чыкса, 2016 елның июнь аенда кулыма «Ата күңеле балада…» дигән мөнәҗәт килеп керде, аңа композитор Әнвәр Шәрәфиев көй дә язды. Аның авторы язучы профессор Фарсель Зыятдинов. Әүвәл ул шулай ук шагыйрә, җырлар авторы Фираясын югалта, бераздан улы Айваз да аны ташлап мәңгелеккә күчә.

Йөрәге сыкрануын, әрнүен, сызлануын, югалтуның кайтарып булмаслыгын аңлау үзеннән-үзе шигъри юлларга иңә. Шәхси кичерешне ачуның иң кулае мөнәҗәт дип табыла. Тора-бара әсәрнең исеме дә үзгәрә. Беренче нөсхәдә «Ата күңеле балада…»ны «Кайтып керерсең күк тоела» исеме алыштыра. Үзгәртү шәкли алым гына булмыйча, Алладан, Раббыбыздан мәрхәмәтлек сорау, ярдәм, өмет итү мотивлары килеп керә.



*Тәңребездән рәхимлек сорап,*
*Хәсрәтемне елап юамын.*
*Раббем кушып бер иртәдә*
*Кайтып керерсең күк тоямын.*

Татар сүз сәнгате Кол Шәриф, Әхмәд Ясәви, Сөләйман Бакыргани, Һ. Сали кебек шагыйрьләр сызган юлга тугрылыклы калып, мөнәҗәтнең офыкларын киңәйтүне дәвам иттерә. Казан ханлыгы чорының бөекләре турында «Сөембикә» (1987), «Колшәриф» (1990), «Мөхәммәдьяр» (1996) кебек мифопоэтик поэмалар авторы Ә. Рәшитнең Мөхәммәд пәйгамбәр образын тудыруга алынуы табигый иде. Шагыйрь ислам динен тотучылар өчен изге затның шигъри сынын тудырганда, тарихи, әдәби чыганакларга таянып иҗат итүе, Мөхәммәдне идеаллаштырып сурәтләвеннән сизелеп тора.

*Кинәт кенә әллә нәрсә булды,*
*Ишек алды якты нурлар белән тулды.*
(Ә. Рәшит. «Мөхәммәд»).

«Пәйгамбәрләр турында кыйсса» шигырендә Н. Әхмәдиев мөнәҗәтләрдә сибелгән фикерләргә таянып, пәйгамбәрләрнең дә адәм балалары булуларына басым ясап, «Аларга да ташлар атканнар, Хак илчесе дип тормаганнар», «Пәйгамбәр дә судан яралмаган, Кендекләре җиргә береккән», дигән җисми күзәтүләре белән уртаклаша.

Г. Сәгыйров «Нух көймәсе» шигырендә халык, милләт язмышын иҗтимагый-фәлсәфи биеклеккә күтәреп сурәтли. «Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендә инновацияләр һәм традицияләр саклау ресурс үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенең хезмәткәрләре 2022 елда Саба, Әтнә, Арча, Аксубай, Буа районнарында, Казан шәһәрендә оештырылган экспедицияләр вакытында дистәләгән мөнәҗәтләр (яңараклары һәм төрле вариантлары) язып алганнар. Башкаручыларның күбесе мәдрәсәләрдә укыган яисә үзлегеннән дини белем алган, нигездә үткән гасырның 1960-1970 елларында туган ханымнар. Ир-ат затыннан бер Ситтигуллин Рафыйл (1962 елгы) гына «Укы Коръән илә намаз» мөнәҗәтен көйләп әйтеп биргән. Яңа язып алынган мөнәҗәтләрнең күбесе җыентыкларга кертелгән булсалар да, үзләренә күпмедер күләмдә замана рухын сыйдырганнары да бар. «Картаябыз димик әле, мөнәҗәтләр көйлик әле», «Буш үткәрмә вакытыңны», «Сабыр итик» һ. б. мөнәҗәтләрне көйләп биргәннәр.

Китерелгән мисаллардан гына да үзеннән-үзе шундый нәтиҗә соралып тора: бәетләр шикелле үк, мөнәҗәтләрнең һаман да язылып торуы аларның тормышчан нигезле булуы һәм кешенең иң авыр мизгел-

ләрдә кулына каләм тоттырган кайгы-хәсрәте белән уртаклашкан әдәби төр дәрәҗәсенә күтәрә, халык, туган телебез исән булганда, аның яшәячәгенә инандыра.

Мөнәҗәтләрне фәнни өйрәнү, кабатланмас үзенчәлекләрен тикшерү юнәлешендә дә эзләнүләр тукталып тормый.

Халык иҗаты белән язма поэзия бердәмлегендә туган, жанрлык хасиятләре, шигырь төзелеше җәһәтеннән төрле, гаруз системасы янында силлабикага корылган мөнәҗәтләрне төркемнәргә бүлүдә барча галимнәрне, җәмәгатьчелекне кәнагатьләндерелек классификацияне эзләү әлегәчә дәвам итә. Мөнәҗәтләрне фәнни-гамәли өйрәнүгә К. Хөснуллин, М. Бакиров, Ф. Урманче, К. Миңнуллин, Ф. Йосыпов, Җ. Зәйнуллин һ. б. галимнәр, һәвәскәрләр җитди өлеш керттеләр.

Мөнәҗәтләрне төркемнәргә бүлүдә фикер төрлелеге яшәсә дә, нигездә мәгънәви эчтәлекләре буенча бер-берсен кабатламаган өч олы — төркемгә «җан авазларыбыз» сыешып бетәләр кебек. Менә алар:

1. Дини мөнәҗәтләр.
2. Фәлсәфи-әхлакый эчтәлекле мөнәҗәтләр.
3. Тормыш-көнкүреш, яшәеш мөнәҗәтләре.

Хәзер кыскача гына булса да, һәр төркемнең зарурлыгын һәм мөстәкыйльлеген раслаучы дәлилләрне шәрехләп үтик.

# *Дини мөнәҗәтләр*

Төрле чорда һәм төбәкләрдә иҗат ителгән дини мөнәҗәтләрнең исемнәреннән үк күренгәнчә, барысы да югары шатлык хисе белән Аллаһны ихластан мактау-данлауга көйләнгәннәр. Бу төр мөнәҗәтләрнең нигезендә Аллаһтан җавап алу, ачыклау, көтелмәгән, җылы, ихласи эндәш-мөрәҗәгать ята. Охшаш сүз-гыйбарәләрне, чагыштыру-сынландыруларны кабатлаган өслүб битараф яки гадәти (түбән) сөйләмне кабул итми. Сүз — бөек, илаһи көч турында бара.

*Барча галәм юк чакта Ул бар иде.*
*Та әзәлдән бар иде, Җәббар иде.*
*Җен, фәрештә һәм адәм — берсе дә юк,*
*Һәм йәнә тугыз фәләк — һич берсе юк.*
(«Бердер Аллаһ, бердер»).
Яисә
*Гамәлне мизанга салган да Аллаһ.*
*Җәннәт капусын ачкан да Аллаһ.*
*Туры юлга күндергән дә Аллаһ.*
*Тәмуг утын сүндергән дә Аллаһ.*
(«Хак — хөкем кылучы — Аллаһ»).

Рамазан аеның соңгы ун көнендә мәчет-мәдрәсәләрдә, авыз ачу мәҗлесләрендә укыла, әйтелә торган «Әлвидагъ» мөнәҗәтләр арасында аерым урын били. Аңа бәя биргәндә, «Әлвидагъ, Әлвидагъ, Әл-Фирак, Әл-Фирак, Йә Шәһри Рамадан» кебек сүз-гыйбарәләрнең кабатлана килүендә, гомумән мөнәҗәтләрнең әүвәл гарәп-фарсы телле ислам мәдәниятендә туганлыгына ишарә саклана. Татар мохитендә әлеге мөнәҗәтнең,

аңа охшаганнарның саклануының бер сәбәбе исламны теләп кабул итү булса, икенчесе — алар үзебездә тәңречелек чорында туган келәү-алкышлар, кешене күмгәндә, бәла-каза килгәндә туган тезмә әсәрләр белән табигый рәвештә кушылып китүләрендә. Гарәп-фарсы мохитендә туган мөнәҗәтләр ислам диненең галәми (идеологик) нигез-өлгесенә утыртылганнар. «Кичер безне, Йә Аллаһ, Ля иляһа илляллаһ», дип мөэмин-мөселманнарның турыдан-туры Аллаһка мөрәҗәгате, ихластан теләкләр теләве, соңрак — мөнәҗәтләр догасы буларак исламны кабул иткән һәр халыкның үз телендә башкарылганнар. Тик гомуми мөрәҗәгатьләрдә генә гарәп-фарсы алынмалары сакланган. Һәр очракта да (күп теллелектә дә) суфыйчылыкның нигезендә яткан гүзәллекнең чыганагы Аллага платоник-гыйффәтле гашыйклык үзәктә торган. Алланы, аның җирдәге илчесе Мөхәммәдне сөю фани дөньяда ук мәңгелек рәхәткә ирешү. Ислам кабул иткән инсан әүвәл «Көндезләрен уразада, Кичләрен без намазда», дип кат-кат кабатлап хисап тотса да, «Кичер безне, Йә Аллаһ», дип ярлыкавын сорап, үтенеп торудан тайчынмый.

«Әлвидагъ» югары өслүбтә «төшерелгән» булса да, дин, ураза тотуның да үз гамәлләре, гадәти төшенчәләр турында да уйланырга мәҗбүр итә.

**«Әлвидагъ» мөнәҗәте**

(Рамазан аеның соңгы ункөнлегендә укыла)

*Әлвидагъ, Әлвидагъ*
*Әл-Фирак, Әл-Фирак*
*Йәә Шәһри Рамадән*
*Көндезләрен ураза*

*Кичләрен без намазда*
*Кичер безне, Йәә Аллах,*
*Ля иляһа илляллаһ*
*Ля иляһа илляллаһ*
*Ля иляһа илляллаһ*
*Коръән иңде бу айда*
*Нурлар иңде бу таңда*
*Ашкын-ашкын, әй бәндә*
*Изгелекләр эшләргә*
*Әлвидагъ, Әлвидагъ*
*Әл-Фирак, Әл-Фирак*
*Йәә Шәһри Рамадән*
*Көндезләрен ураза*
*Кичләрен без намазда*
*Кичер безне, Йәә Аллах,*
*Ля иляһа илляллаһ*
*Ля иляһа илляллаһ*
*Ля иляһа илляллаһ*
*Рамазанның башында*
*Һәрбер бәндә каршына*
*Фәрештәләр иңәрләр*
*Гонаһтан котыл, әй бәндәм диярләр.*
*Әлвидагъ, Әлвидагъ*
*Әл-Фирак, Әл-Фирак*
*Йәә Шәһри Рамадән*
*Көндезләрен ураза*
*Кичләрен без намазда*
*Кичер безне, Йәә Аллах,*
*Ля иляһа илляллаһ*
*Ля иляһа илляллаһ*
*Ля иляһа илляллаһ*

*Рамазан айларында*
*Шайтаннар богауланыр*
*Һәрбер бәндә каршында*
*«Раян» ишеге ачылыр*
*Әлвидагъ, Әлвидагъ*
*Әл-Фирак, Әл-Фирак*
*Йәә Шәһри Рамадән*
*Көндезләрен ураза*
*Кичләрен без намазда*
*Кичер безне, Йәә Аллах,*
*Ля иляһа илляллаһ*
*Ля иляһа илляллаһ*
*Ля иляһа илляллаһ*
*Мөхәммәдүрәсүллаһ.*



Мөхәммәд пәйгамбәрнең дөньяга килүенә багышланган «Мәүлид» мөнәҗәте күләме, гарәп-фарсы лөгатьләреннән кереп калган сүз-гыйбарәләрнең күплеге ягыннан да башкалардан аерылып тора. Ул шәрыкъ әдәбиятында калыплашкан тәүхид (гарәп атамасы — бер итү, берләштерү) жанрында язылган. Әүвәл, монотеистик мәүзугъка, ягъни Мөхәммәд пәйгамбәргә күчкәнче, Алланың берлегенә, гадел бөеклегенә, дөньяны яратуына дан җырлана. «Әүвәл Аллаһ исемен зикер итәем» һәм шуннан соң гына «башка эшемә керешәем», ди мөнәҗәтче, башкаларны да шулай эшләргә, яшәргә чакыра. Башка мөнәҗәтләрдә әйтелгән, Аллаһ кылган бөек гамәлләрне санап китә.

*Һәм әзәлдән бай иде, Җаббар иде.*
*Җен-фәрештә һәм адәм берсе дә юк.*
*Һәм янә тугыз фәләк һичберсе юк.*

Бер Ходай юктан бар итте дөньяны дип, ошбу фикерен кат-кат кабатлаганнан соң, бер васыять сөйләргә вәгъдә итә һәм исемгә чыгарылган «Мәүлид» сүзенә — мәгънәсенә әйләнеп кайта. Дөньяны юктан бар иткән Аллаһның җирдәге илчесе — яраткан нәбие Мөхәммәд пәйгамбәргә күчә. Мөхәммәднең атасы Габдулланы, анасы Әминәне рәхмәт нурында коендыргач, «инде аның килүе булды ул, бер гаҗәп нур, нәкъ кояшның яктысы булды», дип үзенең шатлыгын белдерә. Мөнәҗәтче сөекле пәйгамбәребезнең тууын кешелек уйлап тапкан иң сөенечле мактау сүзләренә, мәдхияви гыйбарәләргә төреп бирә. Мәсәлән, иҗатчы-сөйләүче янына килеп утырган өч хур кызы: «Мостафа килә!» — диеп гәп коралар. Аның бөек шәхес, гыйльми дәүләтнең солтаны булачагын әйтәләр. Төп фикерен тыңлаучыга «Ул Рәсүлнең сөннәтеннән бизмәгез», дигән үтенечен соңгы юлларда әйтеп калдыра.

**Мәүлид**

*Әүвәл Аллаһ исемен зикер итәем*
*Соңра башлап һәр эшкә керешәем!*
*Эш башында кем аны зикер итәр*
*Ул эшен Аллаһ аңа ансат итәр*
*Аллаһ исемен зикер итеп эш башламак*
*Һәркемгә ваҗип тиештер аңламак*
*Булса Аллаһ исеме белән һәр эшең*
*Бушка китмәс эшләгән һәрбер эшең!*
*Шул илә Аллаһ дисә кемнең теле*
*Барча гөнаһы түгелер яфрак кебек.*
*Пакъ булыр Аллаһ исемен зикер иткән*
*Ирешер максадына Аллаһ дигән.*
*Килегез чын күңелдән Аллаһ диик*

*Күзләрдән яшьләр түгеп без аһ итик.*
*Шулай итсәк буш куймас Аллаһ безне*
*Рәхмәте киң, ярлыкар һәммәбезне.*
*Бердер Аллаһ, берлегенә шөбһә юк...*
*Диде Әминә вакыт җитте тәмам,*
*Килә инде дөньяга хәйрел — әнәм.*
*Эсселектән сусадым гаять каты*
*Шул вакыт эчерделәр бер ширбәтин.*
*Ап-ак иде кардан да салкын иде*
*Бу кеби дөньяда һич юк иде.*
*Эчтем аны барлык әгъзәм булды нур*
*Эчмәгән тышым атылды нур*
*Килде бер аккош канат илә очып*
*Аркамнан ул сыйпады монда төшеп.*
*Туды шул сәгатьтә ул солтан иде*
*Нурга тулды барлык сәмәват—зәмин.*
*Гәрчә шәфәгать кирәк исә эзләгез,*
*Ул Рәсүлнең сөннәтеннән бизмәгез.*
*И Мөхәммәд Мостафа син, и Рәсүл,*
*Кыл шәфәгать безләргә яумин-нәүзүн.*
*Гәрдәләр сез буласыз уттан нәҗәт*
*Гыйшык илә, дәрт илә әйтик «Салават»...*

Шул рәвешле, дини мөнәҗәтләр Коръән, аны тәфсилләүче мәгълүматларга, мифологиягә, телдән-телгә күчә килгән хатирәләргә, милли аң рудиментларына таяналар. Күп очракта хыял уены, эчке вә мантыйк сиземләү, иҗатчының фикерләү сәләте, дини-гыйльми әзерлеге әһәмияткә ия. Иң камил мөнәҗәтләр фарсы, гарәп, саф татар телендәгеләре Утыз Имәни, Мәүлә Колый, Шәмсетдин Зәки, Акмулла, Кандалый

каләмнәре казанышы (алданрак искәртелгәнчә, хәзерге сүз осталары да мөнәҗәтне рухи дөньяны психологик нечкәлек белән ачуның иң ышанычлысы саныйлар).

Дини мөнәҗәтләрнең структур-композицион үзенчәлеге әһәмияткә ия. Аларда еш кына «икеләтелгән проекция» алымы кулланыла, иҗатчы әүвәл «читтән торып» олы затларга мәдхия яудыра, соңгы юлларда үзенең барлыгын исенә төшереп, гөнаһларын ярлыкауны, шәфкать көтүен әйтеп тәмамлый. Ул тар эгоист түгел, үтенечен барча мөселман кардәшләре исеменнән әйтә.

Адәм балаларының бар авырлыкларга түзүенә хыялында йөрткән оҗмах ләззәтләренең якты нуры балкып торуы ярдәм итә. «Әманәт», «Иярмәк тиештер сөннәткә», «Потлар егылган бу көн», «Барча инсан нигә шатлана?», «Әйтик әле салаватны», «Хак дингә багышланган гомер» һ. б.

Биредә атап үтелгән классик мөнәҗәтләр һәр инсанны фанилыкта дөрес яшәргә, башка дөньяга әзерләүче гамәлләре шактый уйланылган булуга чакыра.

# *Фәлсәфи-әхлакый эчтәлекле мөнәҗәтләр*

Ислам тәгълиматы адәм баласының фани дөньяда кунак кына, вакытлы гына булуын искә төшереп, тормышның кадерен белеп, шәригать кануннарын үтәп, мәңгелектән курыкмыйча көн итү фәлсәфәсен күңелләргә сеңдерә. Фәлсәфи-әхлакый эчтәлекле мөнәҗәтләр инсанны нинди генә авыр хәл-әхвәлләргә юлыкмасын, һәрдаим Аллаһның кодрәтенә, ярлыкавына ышанырга, Коръән сүрәләрен укып, җанын тәрбияләргә, чистарынырга, эчке коллыктан арыныга, дөнья мәшәкатьләре алдында югалып калмаска өйрәтәләр. Ихласи таянычын Аллаһ һәм ул иңдергән ислам динебез ярдәмендә генә бар авырлыкларны җиңеп, күңел тынычлыгы, җан — тән рәхәте табарсың, — дип язылган «Инандым бер Аллага» мөнәҗәтендә.

*Инандым бер Аллага,*
*Алланың барлыгына,*
*Алланың берлегенә,*
*Бердер илаһым бәнем.*

«Кыз бала», «Аерылгансың балалардан», «Әй, Мостафа Мөхәммәд», «Ялгыз агач», «Торып сахраларга чыгам», «Кайтыр идем туган илгә», «Балакаем, сиңа сүзем» кебек себер татарлары арасыннан язып алынган мөнәҗәтләрдә аерылу сагышы сабырлыкка, түземле, ярдәмчән булырга өндәүләр, өлкәнне олылап, балаларны дини рухта тәрбияләүгә чакырулар төрле төбәкләрдә яшәүче татарлар өчен уртак фәлсәфи-әхлакый юнәлешне тәшкил итәләр.

Фәлсәфи-әхлакый тармакның асылын тәшкил иткән мөнәҗәтләр шундый нәтиҗә кырына алып чыгалар: кеше булган кешенең иң зур рухи байлыгы — күңел күрлеге, дип өйрәтә иман. Ә күңел күрлеге — адәм баласын билгеле бер тәрбияви кысаларда тотучы олы көч. «Күңел байлыгы» һәм фәлсәфи-әхлакый компонентлар берсен-берсе тулыландырып киләләр. Фәлсәфә иҗтимагый аңның төп юнәлеше буларак, игътибарын «дөньяга карашны билгели торган белемгә юнәлтә... Фәлсәфә үзенең үзенчәлеген чиксез тирән һәм гомуми, кешелекнең һәр буынына һәм заманына әһәмиятле булган сорауларын да ачыклый»[1].

Фәлсәфи эчтәлекле мөнәҗәтләр үлем һәм үлемсезлек, табигать, социаль-сәяси мәсьәләләрнең чишелешен Аллага, Коръән өйрәтмәләренә тугрылык, әхлакый бурычларны дөрес аңлау мәсьәләләрен калкытып куялар. Аллага гыйффәтле мәхәббәттә үзен тапкан суфыйның иң зур максаты — үзенең җаны — рухы белән Аллага «кушылып эрү» һәм шул юл белән бу дөньяда ук мәңгелек рәхәткә ирешү.

*Әгәр алсаң бу җанымны, якты әйлә иманымны,*
*Күтәр җитмеш хиҗабыңны, күләем бар дидарыңны.*
(«Бакый әйлә иманымны»).
*Тәндә җаным ничә көн миһман икәндер белмәдем.*
*Үтте гомерем, барысы вәйран икәндер, белмәдем.*
(«Тәндә җаным»).

«Синең биш асылың» мөнәҗәтендә фәлсәфә әхлак кануннары белән кушылып, камил инсан намус, гакыл, әдәп, күңел, сабыр кебек сыйфатларны үзендә туплаган булырга тиеш. Гыйлемле булу кешене бизәүче сыйфат, оҗмах ишекләре ачылганда терәк таяныч

булуына басым ясала. («Гыйлем артыкмы, малмы?» «Гыйлем өстәү фарыздыр», «Дин гыйле ме — татлы җимеш»).

Бу мисаллар мөнәҗәтләрнең югары фәлсәфи-әхлакый сыйфатларны үстерү, саклау бурычын үтиләр.

Фәлсәфи-әхлакый мөнәҗәтләрнең зур өлешен сабырлык мәүзугы алып тора. Ул күпчелек мөнәҗәтләрнең атамаларына ук чыгарыла. «Ходаем, кыйл сабырлардан», «Кеше хәлен кеше белми», «Сабырлык бир, йә Кәрим», «Сабыр бирсен үзе Аллаһ», «Ходай бирсен әҗерләрен». Соңгы мөнәҗәт сабырлык турында уйланулардан аптырап калган шәхеснең эчке монологы, үз — үзе белән сөйләшүеннән гыйбарәт. Бу мөнәҗәтләрдә еш кулланыла торган әдәби алым. Әүвәл мөнәҗәтче туганнарына мөрәҗәгать итеп, аларны да кисәтә.

*Сабыр итик, сабыр итик, сабыр итми ни хәл итик?*
*Сабыр итмичә туганнар, диваналар булып китмик.*

Үзенең халәтен башкалар белән бүлешкәч, аңа җиңеллек килер дип уйлау да ярдәм итми. Үз хәсрәте үзендә кала. Ул бәргәләнә, уйлана һәм Ходайга мөрәҗәгатендә беркадәр вакытлыча булса да юаныч таба.

«Ходаем кыйл сабырлардан!» мөнәҗәтендә әдәбиятта киң таралган капма-каршы кую, ягъни антитеза алымы кулланыла: «сабырларны Ходай сөйгән, сабырсызны ләгыйнь (шайтанның эпитеты) дигән» һәм Ходай аларны сөргән. Мөнәҗәтче кыю, үзенә охшамаганнарга кырыс бәя бирүдән дә тайчынып тормый. «Сабырларның «намнәре» сул як тарафыннан килер,

ди. Үзен ул «ал як» тарафдарларына кертсә дә, Алладан сабырлык сорый.

Күренә ки, мөнәҗәтләр үз холкы, фигыле булган шәхесләрне дә тудыра ала икән.

Мөнәҗәтләрнең сюжет-фабула канвалары, композицияләре бертөслерәк күренсәләр дә, сурәтләү чаралары шигырь төзелешләре, мәгънәгә ярашлы рәвештә, шактый бай һәм төрле.

### Ходаем, кыл сабырлык

*Сабырларны Ходай сөйгән, сабырсызны ләгыйнь дигән,*
*Ләгыйньнәрне Ходай сөргән, Ходаем, кыйл сабырлардан!*
*Сабырларның намәләре килер ал як тарафыннан,*
*Дәки уң як тарафыннан, Ходаем, кыйл сабырлардан!*
*Сабырсызның намәләре килер сул як тарафыннан,*
*Дәки арка тарафыннан, Ходаем, кыйл сабырлардан!*
*Ки тәкъдирдә шулай язган, сабырлык сорыйм алладан,*
*Сабырдарның эше уңган, Ходаем, кыйл сабырлардан!*

### Ходай бирсен әҗерләрен

*Сабыр итик, сабыр итик, сабыр итми нихәл итик?*
*Сабыр итмичә, туганнар, диваналар булып китмик.*
*Сабыр итик, сабыр итик, сабыр итми нихәл итик,*
*Сабырсызның эше мөшкел, сабыр итми кая китик?!*
*Бер Ходаем үзе бирсен бу хәсрәтнең әҗерләрен,*
*Бу хәсрәткә сабыр итсәң,нурлы булыр калебләрең.*
*Алай итеп, болай итеп үтә минем гомерләрем,*
*Кайгы-хәсрәтләр белән күтәрелми күңелләрем.*
*Уйлый башым, уйлый башым, уйлама, башым, төрлесен,*
*Төрле уйлар уйлый-уйлый ялгыз гүрләргә керерсең!*

# *Тормыш — көнкүреш, яшәеш мөнәҗәтләре*

Мөнәҗәтләрнең өченче төркемен тәшкил иткән үрнәкләрендә сүз яшәү мәгънәсе, инсанның тормыштагы урыны, кыйбласы, милли хисләре, туганнары, балалары белән мөнәсәбәтләре, алдарак карап үткән бүлекләр белән уртак сабырлык, гыйлем, үлем һәм үлемсезлек, мәңгелек белән чагыштырганда бер мизгел гомернең кадерен белү хакыйкатьләре турында бара.

Бу төркемгә тәкъдим ителгән, дөресрәге, тартылып торган мөнәҗәтләр сан берәмлеге ягыннан иң күпләре булса да, аларның беришесе жанрлык сыйфатлары тарафыннан бәетләргә, озын, моңлы җырларга якын торалар. Үзара тематик керешү сурәтләү чаралары уртаклыгында, хәтта бердәмлегендә дә сизелә. «Читкә киткән кеше мөнәҗәте», «Кайтыр идем туган илгә», «Ата-ана илә тормак дәүләттер», «Ике былбыл», «Сагынуларга юктыр дәва», «Илне сагынып булам дивана», «Ялгыз ана», «Үги бала зары», «Газиз бәбкәм», «Күрәчәгең уйла, мескен», «Куабыз фани дөньяны», «Әйдә, чыгыйк изге юлга», «Белмәдем» кебек күп санлы көйле, милли рухлы мөнәҗәтләр халкыбызның төп өлешенең дингә, яшәеш кануннарына тугрылыклы булып яшәүләренә мисаллар. Бу бүлеккә кергән мөнәҗәтләрнең үзәгендә «гаилә институтын», ягъни ата-ана һәм балалар арасындагы мөнәсәбәтләрне саклый алмаган кешеләрнең сагыш, юксыну, үкенү кичерешләре.

Туганлык хисләрен саклау изге гамәлләрнең үзәгендә торырга тиешлеге искәртелә.

*Берәр кайтып күрерменме печән чапкан тугайларым?*
*Эчем-бәгъремне шул өзә — еглап калды туганнарым.*
(«Читкә киткән кеше мөнәҗәте»).
*И кардәшләр, бән сезләрне күрсәм иде.*
*Бән дә сезнең белән йөрсәм иде.*
(«Кайтыр идем туган илгә»).
*Кяфер булганнар утта янарлар,*
*Тәмуг эчендә мәңге калырлар.*
*Оҗмахта булыр мөэмин бәндәләр,*
*Дөньяда чакта кыйлса гамәлләр.*
(«Эчәрбез без әҗәл шәрабен»).

Тәкъдим ителгән яшәеш, тормыш-көнкүреш турындагы мөнәҗәтчеләрнең төрле һөнәр, белем дәрәҗәләре буенча аерылып торулары да сизелә. Дини, фәлсәфи-әхлакый мөнәҗәтләрнең укымышлы диндар кешеләр, шәкертләр, суфый шагыйрьләр иҗат итсә, ялгызлык моңын, аерылу сагышын, көн итү авырлыгын, якын кешеңне югалту (бу мәүзугъ бәетләр белән уртак) хәсрәтен сурәтләгән тезмәләр күбрәк хатын-кыз күңеленнән өзелеп төшкәннәр. «Аерылдым балалардан», «Бу сагышның бетәсе юктыр», «Күз өстендә кашым идең», «Сагынуларга юктыр дәва», «Анасыннан аерылган кыз зары», «Илне сагынган булам, дивана», «Кавышырга язсын безгә» һәм биредә аталмаган гаҗәп күп санлы мөнәҗәтләрнең үзәгендә ихласлылык, авыр кайгысы, хәсрәте, җан сыкрануы белән бүлешү һәм һәр низагтан арыну җәһәтеннән Аллаһка, динебезгә сыену. «Синең анаң түгелмени?», «Кылыйк тәүбә», «Әҗәлләргә дәвалар юк», «Мәңгелеккә ташлап киттең, ба-

лам», «Китик без шулай» мөнәҗәтләрен аналарга илаһи мөнәсәбәт, тормыш авырлыгына бирешмичә, якты гамәлгә чакырулар соңрак чорларда язылган мөнәҗәтләрнең рухын билгелиләр. Икешәр юллы мисраглардан торган «Китик без шулай» мөнәҗәтендә милли мәсьәләләр дә калкытып куела. Халыкны гафләт йокысыннан уятып, алга барырга, максатка барып җитергә өнди мөнәҗәтче.

*Алданмыйм бер дә юк бар хыялга*
*Көндин көн алга китик без шулай.*
*Милләтне шуңа әйдәп яхшыга,*
*Чыгып яктыга китик без шулай.*

Мөнәҗәтчеләр җәмгыятебездә үсеш авырлыкларын әйтеп, усалланып алудан да, файдасы булсын дип каты-каты чеметеп алудан да тартынып тормыйлар.

# *Менә шундый заман җитәр*

*Ата-анага хөрмәт бетәр, балалардан шәфкать китәр.*
*Туганнардан рәхим китәр — менә шундый*
*заман җитәр.*
*Дин гыйлемен уку бетәр, мәсҗедләрне вәйран итәр,*
*Галимнәрдән чалма китәр — менә шундый заман җитәр.*
*Ир балада гайрәт бетәр, хатын-кыздан хәят китәр,*
*Балалардан өмет бетәр — менә шундый заман җитәр.*
*Бинадары биек булыр, эче тулы җиһаз булыр,*
*Дин дөньясы бозык булыр — менә шундый заман килер.*
*Галимнәре вәгазь сөйләр, кайберләре гайбәт сөйләр,*
*Адәм хәвеф белән үлер — менә шундый заман җитәр.*
*Атасыз бала күбәер, фахишәлек, зина күп булыр,*
*Мәчетләрдә уен булыр — менә шундый заман җитәр.*
*Гөнаһны һич тә белмәсләр, биш вакыт намаз кылмаслар,*
*Заман каһәрен белмәсләр — менә шундый заман җитәр.*
*Фәкыйрь булса бирә алмас, ару булса күрә алмас,*
*Теле гаеп сөйләп армас — менә шундый заман җитәр.*
*Шундый дөньяга алданып, гомерләре үтеп китәр,*
*Әҗәл вакыты килеп җитәр — менә шундый*
*заман җитәр.*
*Дөньялыкта ямьнәр бетәр, халык китәр уңга-сулга,*
*Изге гамәл һич кылмаслар, бихисап мал булыр кулда.*
*Зур-зур биналар салырлар, ашыгып анда барырлар,*
*Эчендә гауга корырлар — менә шундый заман җитәр.*
*Ир-хатыннар хәмер эчәр, төрле уеннар корырлар,*
*Ислам динен онытырлар — менә шундый заман җитәр.*
*Кяфер исеме киярләр, мине күрсеннәр диярләр,*
*Тәгамнең барын җыярлар — менә шундый заман җитәр.*

*Базарлар да очсызланыр, яңгырлар да сирәк явыр,*
*Хәрәм ашаулар күп булыр — менә шундый заман җитәр.*
*Халык әһле көчсез булыр, хәйләкәр адәм күп булыр,*
*Дин иясе гаҗиз булыр —менә шундый заман җитәр.*
*Балалары түрә булыр, хатыннары солтан булыр,*
*Һәм ирләре коллар булыр — менә шундый заман җитәр.*

Әлбәттә, төрле буын, төбәк галимнәребезнең эзләнүләренә таянып иҗат ителгән әлеге төркемләү дә бәхәс уятырга мөмкин. Уртак байлыгыбызны бәяләүдә фикер төрлелеге булуы табигый хәл — хакыйкать, дөреслек үзара аралашу, фикерләшү барышында гына табыла ала. Шунысы бәхәссез: күңелнең биек һәм бөек киштәсендә урын алып торган мөнәҗәт жанрының үткәне һәм бүгенгесе, милли аңыбызның, телебезнең җан авазы, шигъри юлдашы үткәнебез мирасы гына түгел, ә хәзер дә безнең даими таянычыбыз, киләчәк тормышыбызның якты һәм сүнмәс-сүрелмәс маягы.

Бу рухи кыйммәтләр безнең мәдәниятнең аерылгысыз өлешен тәшкил итәләр һәм халкыбыз аны иң фаҗигале елларда да күңелендә, йөрәгендә саклап яңа буыннарга тапшыра килде. Иншалла!

*Тәлгат Галиуллин,*
*язучы, филология фәннәре докторы,*
*Татарстанның, Россиянең атказанган фән эшлеклесе*

**Кулланылган әдәбият**

Бакиров М. Х. Татар фольклоры. — Казан: Мәгариф, 2008. — Б. 299-348.
Хан кызы / Төз. Ж. Зәйнуллин. — Казан: Мәгариф, 1994. — 95 б.
Садыкова А. Х. Татарские мунажаты в типологическом освещении. — Казань, Тат. кн. издат., 1999.

Нигъмәтҗанов М. Татар халык җырлары. Казан, 1976. — Б. 25.
Сибгатуллина Ә. Татар әдәбиятында суфыйчылык. — Казан, 2000. — Б. 334.
Хөнсуллин К. М. Мөнәҗәтләр һәм бәетләр. — Казан: Раннур. — 724 б.

# Дини мөнәҗәтләр

## Укы Коръән илә намаз

*Газраил катыйлганчы,*
*Әҗәл угын кадаганчы*
*Билең-телең тотылганчы,*
*Укы Коръән илә намаз.*

*Сузып «кабыкка» салганчы*
*Илтеп гүрләргә куйганчы,*
*Җавапларыңны биргәнче*
*Укы Коръән илә намаз.*

*Укы иртән намазыңны*
*Кошлар тыңлар авазыңны,*
*Ышанма углың, кызыңа*
*Укы Коръән илә намаз.*

*Булырсың әһлеңнән ерак*
*Киярсең җиңсез яфрак,*
*Өсте такта, төбе туфрак*
*Шул өеңне уйла мескен.*

*Шайтан сиң (г)а сөялмәсен,*
*Тезгенеңне бәйләмәсен,*
*Хакка дошман әйдәмәсен*
*Укы Коръән илә намаз.*
*Укы Коръән илә намаз.*

*Башкара: Ситтигуллин Рафыйль Фәтхрахман улы (1962 елда туган).*
*Язып алынды: Әтнә районы Иске Өҗем авылы.*
*Язып алу вакыты: ноябрь, 2022 ел.*

## Аллаһыма шөкер кылам...

*Аллаһыга шөкер кылам — исәнлек биргәненә*
*Аякларым йөргәненә, күзләрем күргәненә;*

*Аллаһыга шөкер кылам — биргән нигъмәтләренә*
*Аятьләрне ятлар өчен зиһеннәр биргәненә;*

*Аллаһыга шөкер кылам — якты көн биргәненә*
*Күктән яңгырлар яудырып, иген үстергәненә;*

*Аллаһыга шөкер кылам — караңгы төннәренә*
*Намазларны укыр өчен ярдәмен биргәненә;*

*Аллаһыга шөкер кылам — ураза биргәненә*
*Бәндәләрнең гөнаһларын ярлыкыйм дигәненә;*

*Аллаһыга шөкер кылам — ак карлы кышларына*
*Җәйге матур, ал таңнарда сайраган кошларына.*

*Аллаһыга шөкер кылам — сабырлык биргәненә*
*Сабырлыкның савапларын бирермен дигәненә.*

*Аллаһыга шөкер кылам — иманга кайтканыма*
*Намаз укып, Коръән укып, тынычлык тапканыма.*
*Намаз укып, Коръән укып, тынычлык тапканыма.*

*Башкара: Халикова Фәридә Фәтхрахман кызы (1958 елда туган).*
*Язып алынды: Әтнә районы Олы Бәрәзә авылы.*
*Язып алу вакыты: ноябрь, 2022 ел.*

## Пәйгамбәребез Мөхәммәд

*Раббым Аллаһтыр минем*
*Динем исламдыр минем*
*Кыйблам кәгъбәдер минем*
*Бер-бер Иляһем минем.*
*Аллаһның сүзе Коръән,*
*Пәйгамбәренә килгән.*
*Безгә ул китап булган*
*Бер-бер Иляһем минем.*
*Адәмдер минем атам*
*Хавадыр минем анам,*
*Милләтемдер Ибраһим*
*Бер-бер Иляһем минем.*
*Сорау сөальләрне дә*
*Җиңел кичер Иляһем.*
*Янә болардан башка*
*Пәйгамбәрем ни әйтсә.*
*Аллаһтан ни китерсә,*
*Инандым мин Иляһем.*
*И Мостафа Мөхәммәд*
*Иляһемнең дусты син.*
*Безгә шәфәгатьче син*
*И Мөхәммәд Мостафа,*
*СәлАллаһугаләйкә*
*Йә Мостафа Мөхәммәд.*
*Җиде кат күк кичтең син*
*Гарыштан да аштың син*
*Иляһ белән сөйләштең*
*И Мостафа Мөхәммәд.*
*СәлАллаһугаләйкә*

Йә Мостафа Мөхәммәд.
Шәригатьне сөйләдең
Тарыйкатьне эзләдең,
Хакыйкатьне күзләдең
Син Мостафа Мөхәммәд.
СәлАллаһугаләйкә
Йә Мостафа Мөхәммәд
Бу дөньяны сөймәдең,
Туйганчы аш имәдең,
Хак коллыгың куймадың,
Ул Мостафа Мөхәммәд.
СәлАллаһугаләйкә
Йә Мостафа Мөхәммәд.
Тәкъдир булган әҗәлдән
Ятим калган атадан
Һәм шәфкатьле анадан
Син Мостафа Мөхәммәд,
СәлАллаһугаләйкә
Йә Мостафа Мөхәммәд.
Теләмәде атасын
Һәм шәфкатьле анасын
кылды өммәт догасын,
Ул Мостафа Мөхәммәд
СәлАллаһугаләйкә
Йә Мостафа Мөхәммәд.
Өммәте өчен көйгән
Күп хәсрәтләр дә күргән
Күп михнәтләрдә җиткән,
Ул Мостафа Мөхәммәд
СәлАллаһугаләйкә
Йә Мостафа Мөхәммәд.

*Ачлыкта сабыр иткән*
*Нәфестә җәбер иткән*
*Өммәт өчен җәһат иткән*
*Ул Мостафа Мөхәммәд*
*СәлАллаһугаләйкә*
*Йә Мостафа Мөхәммәд*
*Көннәрдә руза булган*
*Төннәрдә уяу булган*
*Өммәт өчен кайгырган,*
*Ул Мостафа Мөхәммәд*
*СәлАллаһугаләйкә*
*Йә Мостафа Мөхәммәд.*
*Атасыннан да кичкән*
*Анасыннан да кичкән*
*Өммәт өчен ах иткән,*
*Ул Мостафа Мөхәммәд*
*СәлАллаһугаләйкә*
*Йә Мостафа Мөхәммәд.*
*Күп рәхмәт булсын сиңа*
*Чук сәлам булсын сиңа*
*Шәфәгать әйлә син безгә,*
*Әй Мостафа Мөхәммәд*
*Шәфәгать әйлә син безгә*
*Әй Мостафа Мөхәммәд,*
*СәлАллаһугаләйкә*
*Йә Мостафа Мөхәммәд.*

*Башкара: Җиһаншина Фәрхинур Барый кызы*
*(1957 елда туган).*
*Язып алынды: Әтнә районы Югары Көек авылы.*
*Язып алу вакыты: ноябрь, 2022 ел.*

## И Аллаһым, диде Муса

*И Аллаһым, диде Муса*
*Җәннәт булыр микән миңа?*
*Сиңа җәннәт булыр Муса-*
*Ата-анаң разый булса.*

*И Аллаһым, диде Муса*
*Җәннәт булыр микән миңа?*
*Сиңа җәннәт булыр Муса-*
*Кыз туганың разый булса.*

*И Аллаһым, диде Муса*
*Җәннәт булыр микән миңа?*
*Сиңа җәннәт булыр Муса-*
*Күршеләрең разый булса.*

*И Аллаһым, диде Муса*
*Җәннәт булыр микән миңа?*
*Сиңа җәннәт булыр Муса-*
*Гарипләрнең хәлен белсәң.*

*И Аллаһым, диде Муса*
*Җәннәт булыр микән миңа?*
*Сиңа җәннәт булыр Муса-*
*Аллаһның барлыгын белсәң.*

*Авыр булса дөньялары,*
*Урап алса сагышлары,*
*Бирешмә бу сынавына*
*Аллаһ сөя сабырларны.*

*Гомерләр ул бик тиз үтә*
*Һәммәбездән төрле китә.*
*Күңел булсын изгелектә*
*Аллаһка шөкер дип яшә.*

*Ярдәмеңнән аермасын*
*Рәхмәтеннән калдырмасын,*
*Кайгы җилләре какмасын,*
*Бары тик Аллаһ сакласын.*

*Бер Ходаем гафу әйлә,*
*Теләгебезне кабул әйлә,*
*Фирдәүс җәннәтләреңне*
*Барчабызга насыйп әйлә.*
*Фирдәүс җәннәтләреңне*
*Барчабызга насыйп әйлә.*

*Башкара: Җиһаншина Фәрхинур Барый кызы*
*(1957 елда туган)*
*Язып алынды: Әтнә районы Югары Көек авылы.*
*Язып алу вакыты: ноябрь, 2022 ел.*

## Ля иляһ илляллаһ

*«Ля иляһе илляллаһ»ны әйтик әле бергәләп,*
*Авыр мәхшәр көннәрендә азан әйлик бергәләп.*

*«Ля иляһе илляллаһ»ны әйтик әле бергәләп,*
*Караңгы сират күпереннән үтик әле бергәләп.*

*«Ля иляһе илляллаһ»ны әйтик әле бергәләп,*
*Сигез оҗмах ишегеннән керик әле бергәләп.*

*«Ля иляһе илляллаһ»ны әйтик әле бергәләп,*
*Кәүсәр елга буйларында йөрик әле бергәләп.*

*«Ля иляһе илляллаһ»ны әйтик әле бергәләп,*
*Кәүсәр шәраб суларын да эчик әле бергәләп.*

*«Ля иляһе илляллаһ» ны әйтик әле бергәләп*
*Бер Аллаһның дидарын да күрсәк иде бергәләп.*

*«Ля иляһе илляллаһы» сираттан аман кичерер*
*«Ля иляһе илляллаһы» тәмуг утын очырыр.*

*«Ля иляһе илляллаһы» гайбтин ризык таптырыр,*
*«Ля иляһе илляллаһы» ризыгыңны арттырыр.*

*«Ля иляһе илляллаһы» тәмуг утын уздырыр*
*«Ля иляһе илляллаһы» мәртәбәгә менгерер.*

*«Ля иляһе илляллаһы» мизаннарга салыныр*
*«Ля иляһе илляллаһы» дин кальбенә нур булыр.*

*«Ля иляһе илляллаһы» мөэминнәргә юлдаш ул*
*«Ля иляһе илляллаһ» Мөхәммәд рәсүлуллаһ.*

*Башкара: Зарипова Рәйхана Галимулла кызы*
*(1953 елда туган)*
*Язып алынды: Әтнә районы Олы Бәрәзә авылы.*
*Язып алу вакыты: ноябрь, 2022 ел.*

## «Ля иляһ(а) илляллаһу» — изге сүзләр изгесе...

*«Ля иляһ(а) илляллаһу» — изге сүзләр изгесе,*
*«Ля иляһ(а) илляллаһу» — ике җиһан көзгесе.*
*«Ля иляһ(а) илляллаһу» иман нурын арттырыр,*
*«Ля иляһ(а) илляллаһу» сираттан тиз кичерер,*
*«Ля иляһ(а) илляллаһу» кәүсәр-шәраб эчерер.*
*«Ля иляһ(а) илляллаһу» хәләл ризык таптырыр.*
*«Ля иляһ(а) илляллаһ»ны әйтми торма берзаман,*
*«Ля иляһ(а) илляллаһ» ны әйтмәгәннәр бик яман.*
*«Ля иляһ(а) илляллаһ» ның карамагыз әзенә,*
*«Ля иляһ(а) илляллаһу» — мәңге бетмәс хәзинә.*



*Башкара: Нигъмәтҗанова Мәрвәр Мөбәрәкша кызы*
*(1954 елда туган)*
*Язып алынды: Әтнә районы Күлле-Киме авылы.*
*Язып алу вакыты: ноябрь, 2022 ел.*

## Бердер Иляһым бәнем

*Инандым бер Аллага, Алланың барлыгына,*
*Алланың берлегенә, бердер Иляһым бәнем.*
*Бер Иляһым, үзең Сән һәр нәрсәне бар иткән,*
*Һәркемгә ризык биргән, бердер Иляһым бәнем.*
*Һәр нәрсәне белерсең, бар нәрсәне күрерсең,*
*Тавышын ишетерсең, бердер Иляһым бәнем.*
*Иляһым сүзе — Коръән, пәйгамбәремә иңгән,*
*Безгә ул китап килгән, бердер Иляһым бәнем.*
*Адәмдер — бәнем Атам, Хавадыр — бәнем анам,*
*Үземдер бән — мөселман, бердер Иляһым бәнем.*
*Ул Мөхәммәд Мостафа — пәйгамбәремдер бәнем,*
*Шәфәгатьчемдер бәнем, бердер Иляһым бәнем.*
*Раббым — Аллаһдыр бәнем, динем — Исламдыр бәнем,*
*Шәфәгатьчемдер бәнем, бердер Иляһым бәнем.*
*Икътикадта мәзһәбем — әһле сөннәттер бәнем,*
*Гамәлдә имам Хәнәфи мәзһәбедер мәзһәбем.*

*Башкара: Әхмәтвәлиева Сәрмәдия Хәбибулла кызы*
*(1949 елда туган).*
*Язып алынды: Аксубай районы, Яңа Үзи авылы.*
*Язып алу вакыты: декабрь, 2022 ел.*

## Инандым бер Аллага

*Инандым бер Аллаһка*
*Аллаһның барлыгына*
*Аллаһның берлегенә,*
*Бердер Иляһем бәнем*
*Аллаһның берлегенә.*
*Бердер Иляһем бәнем.*

*Бер Аллаһым үзеннән*
*Һәр нәрсәне бар иткән*
*Һәркемгә ризык биргән.*
*Бердер Иляһем бәнем*
*Һәркемгә ризык биргән*
*Бердер Иляһем бәнем.*

*Аллаһым сүзе — Корьән*
*Пәйгамбәрләрдән килгән*
*Безгә ул китап булган.*
*Бердер Иляһем бәнем*
*Безгә ул китап булган*
*Бердер Иляһем бәнем.*

*Ул Мөхәммәд Мостафа*
*Пәйгамбәремдер бәнем*
*Шәфәгатьчемдер бәнем.*
*Бердер Иляһем бәнем*
*Шәфәгатьчемдер бәнем*
*Бердер Иляһем бәнем.*

*Адәмдер бәнем атам,*
*Хавадыр бәнем анам*
*Милләтемдер Ибраһим.*
*Бердер Иляһем бәнем*
*Милләтемдер Ибраһим*
*Бердер Иляһем бәнем.*

*Башкара: Җиһаншина Хөрия Сәфәргали кызы*
*(1965 елда туган )*
*Язып алынды: Буа районы, Яңа Чәчкап авылы.*
*Язып алу вакыты: декабрь, 2022 ел.*

## И дусларым, гамәл кылыйк

*И дусларым, гамәл кылыйк*
*Гамәлдән соң дога кылыйк.*
*Бер Ходайның үзеннән без,*
*Фирдәүс җәннәтен сорыйк.*
*Салаватларны күп әйтик,*
*Кылыйк гамәл таң атканчы,*
*Укыйк Коръән, укыйк тәһлил,*
*Кара туфраклар басканчы.*
*Бу дөньялар безгә фани*
*Ахирәт юллары бакый.*
*Кыямәт көннәре булганда,*
*Барча тәнем тетрәп торыр.*
*Шул вакытта Рәсүлебез,*
*Өммәтем дип, безне сорар.*
*Рәсүлулла сорар безне,*
*Өммәтемне ярлыка дип,*
*Шушы булган өммәтемне,*
*Тәмугларда калдырма, дип.*
*Хода бәндәм, дияр Аллаһ,*
*Ярлыкадым, өммәтеңне,*
*И, Хәбибем, синең хакка,*
*Багышладым, җәннәтемне.*
*Иманлы булган бәндәне*
*Фәрештәләр каршы алыр,*
*Ходайның рәхмәте белән*
*Җәннәтләргә алып барыр.*
*Гөнаһларны гафу әйлә,*
*Күндерсәнә изге юлга,*
*Ходайның рәхмәте белән*

*Намазларны бир син миңа.*
*Сабыр итик, сабыр итик,*
*Сабыр итүләр хуш булыр,*
*Сабыр итмәгән бәндәнең*
*Гамәл дәфтәре буш булыр.*
*Ахирәт хәлләрен яздым,*
*Дәфтәр алып юллар буйлап,*
*Күңлем таш булса да эрер,*
*Кыямәт хәлләрен уйлап.*
*Карап йөрим кара җиргә,*
*Керермен дип кара гүргә,*
*Атам-анам белән бергә*
*Булуларны насыйп әйлә.*
*Их, дусларым, сезгә әйтәм,*
*Күктә дә бит пәйгамбәр бар.*
*Үзебез мөэмин, динебез ислам,*
*Шөкерана кылырлык бар.*
*Үзебез мөэмин, динебез ислам,*
*Шөкер Ана кылырлык бар.*

*Башкара: Фатыйхова Гөлнур Хафиз кызы*
*(1967 елда туган).*
*Язып алынды: Аксубай районы, Яңа Үзи авылы.*
*Язып алу вакыты: декабрь, 2022 ел.*

## Дин гыйлеме, татлы җимеш

*Калды безгә бик зур нигъмәт*
*Дин гыйлеме — бик зур хикмәт,*
*Уйласак, безгә зур хөрмәт*
*Без — Мөхәммәд өммәтебез.*
*Калмады алтын вә көмеш,*
*Калды безгә бик зур өлеш.*
*Дин гыйлеме — татлы җимеш,*
*Без — Мөхәммәд өммәтебез.*
*Һич тә сүзем түгел ялган,*
*Мирас булып гыйлем калган.*
*Шул гыйлемнән өлеш алган,*
*Без — Мөхәммәт өммәтебез.*
*Дин-исламга сабит булыйк,*
*Гыйбадәтләрне төз кылыйк.*
*Рәсүлдән өлеш алыйк,*
*Без — Мөхәммәд өммәтебез.*
*Дин-исламга җан багышлыйк,*
*Бозык гамәлләрне ташлыйк.*
*Изге гамәлләрне башлыйк,*
*Без — Мөхәммәд өммәтебез.*
*Буш үткәрмик гомерләрне,*
*Сафландырыйк күңелләрне,*
*Кылыйк изге гамәлләрне,*
*Без — Мөхәммәд өммәтебез.*



*Башкара: Хасанова Рәзинә Гәрәй кызы*
*(1959 елда туган)*
*Язып алынды: Буа районы, Түбән Наратбаш авылы*
*Язып алу вакыты: ноябрь, 2022 ел.*

## Әлвадагъ

*(Рамазан аеның соңгыункөнлегендә укыла)*

*Әлвадагъ, Әлвадагъ*[3]
*Әл Фирак, Әл-Фирак*[4]
*Йә Шәһре Рамадән*[5]
*Көндезләрен ураза*
*Кичләрен без намазда.*
*Кичер безне, йә Аллаһ,*
*Ля Иляһе илляллаһ, ля Иляһе илляллаһ,*
*ля Иляһе илляллаһ.*
*Коръән иңде бу айда*
*Нурлар иңде бу төндә*
*Ашкын-ашкын, әй бәндә*
*Изгелекләр эшләргә.*
*Әлвадагъ, Әлвадагъ*
*Әл-Фирак, Әл-Фирак*
*Йә Шәһре Рамадән!*
*Көндезләрен ураза*
*Кичләрен без намазда*
*Кичер безне, йә Аллаһ,*
*Ля Иляһе илляллаһ, ля Иляһе илляллаһ,*
*ля Иляһе илляллаһ.*
*Рамазанның башында*
*Һәрбер бәндә каршына,*
*Фәрештәләр иңәрләр*

---

[3] Әлвадагъ сүзен респондент сөйләмендә калдырдык.

[4] Әл-Фирак — аерылу.

[5] Шәһре Рамадән, Рамазан сүзтезмәләре халык арасында киң таралган.

*Гөнаһтан котыл, әй бәндә диярләр.*
*Әлвадагъ, Әлвадагъ,*
*Әл-Фирак, Әл-Фирак,*
*Йә Шәһре Рамадән!*
*Көндезләрен ураза*
*Кичләрен без намазда*
*Кичер безне, йә Аллаһ,*
*Ля Иляһе иллаллаһ, ля Иляһе иллаллаһ,*
*ля Иляһе иллаллаһ.*

*Рамазан айларында*
*Шайтаннар богауланыр.*
*Һәрбер бәндә каршында*
*«Раян» ишеге ачылыр.*
*Әлвадагъ, Әлвадагъ.*
*Әл-Фирак, Әл-Фирак,*
*Йә Шәһре Рамадән!*
*Көндезләрен ураза*
*Кичләрен без намазда*
*Кичер безне, йә Аллаһ,*
*Ля Иляһе иллаллаһ, ля Иляһе иллаллаһ,*
*ля Иляһе иллаллаһ,*
*Ля Иляһе иллаллаһ, Мөхәммәд рәсүлуллаһ!*

*Башкара: Сафина Фәимә Корбангали кызы*
*(1960 елда туган)*
*Язып алынды: Саба районы Тимершык авылы.*
*Язып алу вакыты: ноябрь, 2022 ел.*

## Мәүлид мөнәҗәтләре

*Әүвәл Аллаһ исемен зикер итәем*
*Соңра башлап һәр эшкә керешәем!*
*Эш башында кем аны зикер итәр*
*Ул эшен Аллаһ аңа ансат итәр*
*Аллаһ исемен зикер итеп эш башламак*
*Һәркемгә вәҗип тиештер аңламак*
*Булса Аллаһ исеме белән һәр эшең*
*Бушка китмәс эшләгән һәрбер эшең!*
*Шул илә Аллаһ дисә кемнең теле*
*Барча гөнаһы түгелер яфрак кебек.*
*Пакъ булыр Аллаһ исемен зикер иткән*
*Ирешер максадына Аллаһ дигән.*
*Килегез чын күңелдән Аллаһ диик*
*Күзләрдән яшьләр түгеп без аһ итик.*
*Шулай итсәк буш куймас Аллаһ безне*
*Рәхмәте киң, ярлыкар һәммәбезне.*
*Бердер Аллаһ, берлегенә шөһбә юк*
*Сөйләгәннәр ялгышып дөнья тулы (ук)*
*Барча галәм юк икән ул бар иде*
*Һәм әзәлдән бай иде, Җаббар иде.*
*Җен-фәрештә һәм адәм берсе дә юк*
*Һәм янә тугыз фәләк һичберсе юк.*
*Гарши-көрси, ай-кояш – берсе юк.*
*Барча җаннан әүвәл үк ул бар иде.*
*Кодрәт белән боларны бар әйләде*
*Берлегенә барча икрар әйләде.*
*Бу хосуста күп сүзгә хаҗәт тә юк*
*Аллаһ бердер, бардыр ул, башкасы юк.*

*И, газизләр инде килде сүз башы*
*Тыңлагыз сез агызып күз яшен.*
*Бер васыять сөйләмәкче буламын*
*Ул васыять ошбудыр, тот колагын.*
*Һәркем аны тыңласа, тотар исә*
*Ул кешедән һәр заман хушбуй исә.*
*Кылыр Аллаһ шул кешегә рәхмәтен*
*Мәүлид — Нәбинең кылса хөрмәтен.*
*Тыңлаганар һәм табар фазиләтен*
*Укыса нәсеп-нисап шамаилен!*
*Рухыны шат итәек сәләт илә*
*Әһле Бәкер, әсхәбләр белән бергә.*
*Ул туган көннәрне хөрмәт иткән*
*Тыңла шул кыйссасыны ихлас белән.*
*Бер Ходай юктан итте дөньяны*
*Мостафаның нуры белән нурлады.*
*Һәм бар итте элек шул нуры ни ул*
*Һәм барлыкның зурысы булды ул.*
*Ошбу нурдан күк йөзенең сафлыгы*
*Ошбу нурдан җир йөзенең барлыгы.*
*Гарши-көрси ошбу нурдан бар була*
*Дөньяның күрке шушы нурдан гына.*
*Булмаса ул, булмас иде берни дә*
*Һәм яратмас иде җирне күкне.*
*Булмаса да булмас иде бер адәм*
*Һәм яратмас иде дөньяны тәмам.*
*Яратылды аның өчен һәммәсе*
*Аның өчен бар итте бәндәсе ни*
*Хак яратты хәзрәти Адәмне ул*
*Һәм балкыды маңгаенда ошбу нур*

*Шул сәбәпле мәртәбәле булды ул*
*Ошбу нур хәлифә итте һәм аны.*
*Һәм фәрештәләргә юлдаш итте аны.*
*Сәҗдә кылды һәр фәрештә шул сәбәп.*
*Күккә ашты хөрмәти һәм шул сәгать*
*Соңрак бу хәл бар баласын күчеп*
*Килде Габдуллага хәтле ул үсеп.*
*Һәм аның да маңгаеннан чыкты нур*
*Нәкъ кояш кебек күк ялтырады бу нур.*
*Вакыты җиткәч күчте нур Габдулладан*
*Балкыды ул хәзрәти Әминәдән*
*Йөкле булды ул Хәбибнең анасы*
*Җитте туар вакты җую данәсе*
*Әминә хатын Мөхәммәд анасы*
*Ул сәдәфтән туды энҗе данәсе.*
*Ул Мөхәммәд дөньяга хөрмәт итәр*
*Вакыты җитте килмәккә хәерел Бәшәр.*
*Инде аның килүе булды анык*
*Күп сәламәт пәйда булды алдан ук.*
*Ул рабигыль — әүвәл аенда иде*
*Уникенче кичәсе дүшәмбе иде.*
*Күрдем, диде ул Мөхәммәд анасы,*
*Бер гаҗәеп нур, нәкъ кояшның яктысы!*
*Ялт итеп чыкты өемнән шул заман*
*Күкләргә тик нур белән тулды җиһан.*
*Һәм дә һавада түшәлдә бер түшәк*
*Аты сөндүс, түшәгән аның мәләк.*
*Өч әләм тагы куйдылар өч җиргә*
*Аралары бик ерак бер-беренә.*
*Бере Мәшрикъ, бере Мәгърибтә аның*

*Берсе нәкъ уртасында Кәгъбәнең.*
*Белдем аннан ул мөбәрәкнең нурын.*
*Заһир булды килмәсеннән әүвәллин.*
*Инде күптән күп фәрештә сафи саф*
*Кәгъбә кебек кылдылар өем таваф.*
*Кинәттән өч хур кызы пәйда булды*
*Кайдан килгәннәрен аңлап булмады.*
*Өчесе дә яныма утырдылар,*
*«Мостафа килә!» диеп гәп кордылар.*
*Диделәр: «Улың кебек хөрмәтлене,*
*Ул Аллаһ һичбер анага бирмәде!*
*Бик олугъ дәүләт иясе буласың*
*Холкы күркәм бер угыл тудырасың!*
*Бу угыл гыйлми дәүләтенең солтаныдыр.*
*Бу угыл тәүхиде гыйрфан канидер!”*
*Сыйфатын шул рәвешчә аңлаттылар*
*Ул мөбәрәк нур белән шатландылар!*
*Диде Әминә вакыт җитте тәмам,*
*Килә инде дөньяга хәйрел – әнәм.*
*Эсселектән сусадым гаять каты*
*Шул вакыт эчерделәр бер ширбәтин.*
*Ап-ак иде кардан да салкын иде*
*Бу кеби дөньяда һич юк иде.*
*Эчтем аны барлык әгъзәм булды нур*
*Эчмәгән тышым атылды нур*
*Килде бер аккош канат илә очып*
*Аркамнан ул сыйпады монда төшеп.*
*Туды шул сәгатьтә ул солтан идең*
*Нурга тулды барлык сәмәват—зәмин.*
*Гәрчә шәфәгать кирәк исә эзләгез,*

*Ул Рәсүлнең сөннәтеннән бизмәгез.*
*И Мөхәммәд Мостафа син, и Рәсүл,*
*Кыл шәфәгать безләргә яумин-нәүзүн.*
*Гәрдәләр сез буласыз уттан нәҗәт*
*Гыйшык илә, дәрт илә әйтик «Салават»...*

*Башкара: Курмакаева Сания Якуб кызы*
*(1967 елда туган).*
*Язып алынды: Казан шәһәре.*
*Язып алу вакыты: ноябрь, 2022 ел.*

## Мәүлид мөнәҗәтләре

*Рәсүлуллаһ бораклары*
*Көмештәндер тояклары*
*Ихлас белән гамәл кылыйк*
*Без бу дөнья кунаклары.*

*Аллага гашыйк булганнар*
*Зикердә булганнар алар.*
*Шулар белән булыр өчен*
*Зикер әйтик мөселманнар.*

*Шәфәгатен өмет итеп*
*«Салават»лар әйтсәк иде.*
*Бер Аллаһым кабул итеп*
*Морадларга җитсәк иде.*

*Алланың дусты пәйгамбәр*
*Туган ай бу мөселманнар.*
*Бу ай бәйрәм һәркөн шатлык*
*Мөкатдәс бик шәриф ай бу.*

*Туды Мәккә шәһәрендә*
*Рабигүль әүвәл аенда.*
*Дүшәмбе көн уникенче сәхәр*
*Вакыт иде таң алдында.*

*Рәсүллуллаһ туган чакта*
*Сөннәтле күзе сөрмәле*
*Туу белән сәҗдә кылды*
*Яуды Аллага рәхмәте.*

*Аңар өмет булу белән*
*Безне хөрмәтләде ул.*
*Вә көне-төне хәйри өммәте дип*
*Хәбәр бирде үзе ул.*

*Рәсүлулла намазда ул*
*Башындадыр аның тажы.*
*Өммәтем, өммәтем, диеп*
*Агадыр күзендин яше.*
*Агадыр күзендин яше.*

*Рәсүлулла Раузасында*
*Зикер әйтеп сайрый кошлар.*
*Шул кошлардан гыйбрәт алып*
*«Салават»лар әйтик дуслар.*

*«Салават»ка кушылыгыз*
*«Салават»ларын белгәннәр.*
*Җәннәт ишеген ача алмаслар.*
*«Салават»лар әйтмәгәннәр*
*«Салават»лар әйтмәгәннәр.*

*Башкара: Курмакаева Сания Якуб кызы*
*(1967 елда туган).*
*Язып алынды: Казан шәһәре.*
*Язып алу вакыты: ноябрь, 2022 ел.*

# Фәлсәфи-әхлакый эчтәлекле мөнәҗәтләр

## Әрвахларыбыз шат булсын

*Килеп кердем өегезгә*
*Дога бирдем түрегездә,*
*Иман нуры йөзегездә*
*Нурлар булсын йортыгызда.*
*Килеп кердем өегезгә*
*Тәсбих нуры йөзегездә.*
*Тәсбих әҗерләрен бирсен*
*Бер Ходаем үзегезгә.*
*Мәҗлесегез күркәм булсын*
*Өегезгә фәрештә тулсын,*
*Догаларыбыз кабул булсын.*
*Әрвахларыбыз шат булсын.*
*Ошбу өйнең хуҗасына*
*Дәхли балаларына,*
*Дәхи ата-анасына*
*Шәфкать бирсен рәсүлуллаһ.*
*Сагынып килдем үзегезне*
*Дәхи күрдем йөзегезне*
*Безне каршы алган кебек*
*Бәхет каршыласын сезне.*
*Әй, туганнар, сыйладыгыз*
*Тәмле нигъмәтләр белән.*
*Ходаем сыйласын сезне*
*Җәннәт нигъмәтләре белән.*
*Минем бүләгем юк сезгә*
*Тел бүләккәйләрем сезгә.*
*Ходай биргән бүләгем бар*
*Хәер дога кылам Сезгә.*
*Ходай гомерләрне бирсә*

*Тагы да бер күрешербез,*
*Иманыбыз камил булса*
*Җәннәтләрдә очрашырбыз.*
*Әй туганнар беләсезме,*
*Гомер үтә сизәсезме?*
*Бу гомерләр үткәннән соң*
*Ни булырын беләсезме?*
*Бу дөньядан китәрбез лә*
*Әҗәл суын эчәрбез лә.*
*Бу гомерләр үләр булсак*
*Кыяматтә нишләрбез лә?*
*Укы дидегез, укыдым*
*Күңелләрегез ачылсын.*
*Сигез җәннәт эчләренә*
*Ризыкларыбыз чәчелсен (Амин).*
*Яшьли вафат булганнар күп*
*Әрни йөрәк ярасы,*
*Мәетләргә дога кылыйк*
*Без дә бит шунда барасы.*
*И кардәшләр, башыбызга*
*Авыр хәлләр киләсе бар,*
*Кабер дигән тар ләхеткә*
*Һәммәбезнең керәсе бар.*
*Багышларбыз, искә алырбыз*
*Онытмабыз аларны да,*
*Ходай кабул итсә иде*
*Укыган догаларны.*

*Башкара: Гимадиева Гатифә Котдус кызы*
*(1957 елда туган).*
*Язып алынды: Саба районы, Туктар авылы.*
*Язып алу вакыты: декабрь, 2022 ел.*

## Раббым Аллам Кадыйр мәүләм, бәни салдың бу зинданга

*Раббым Алла Кадыйр мәүләм,*
*Бәни салдың бу зинданга.*
*Кыямәт көне булганда*
*Гафу кыл гөнаһларны.*

*Тәмугның төтене кара*
*Карасаң күзләрең тала.*
*Әй, гомерләр үтеп бара*
*Биш вакыт намазлар кала.*

*Газраил килде кунак*
*Чаршавымны корыгыз.*
*Җан бирүләр бик авыр*
*Алла әйтеп торыгыз.*

*Җан ачыс(г)ын мин беләмен*
*Газраил җан алганда.*
*Тагын шундый хәлләрем бар*
*Гүрдә ялгыз калганда*
*Гүрдә ялгыз калганда.*

*Намаз фарыз һәрбер колга*
*Фәкыйрьгә һәм байга, толга.*
*Кыямәт көне авыр булыр*
*Намаз укымаган колга.*
*Намаз укымаган колга.*

*Иртән торып, «Бисмиллә» әйтеп*
*Зикер әйтик бер Аллага.*
*Мәңгелек суын эчмәдек*
*Алданмыйк бу дөньяга,*
*Алданмыйк бу дөньяга.*

*Башкара: Курмакаева Сания Якуб кызы*
*(1967 елда туган).*
*Язып алынды: Казан шәһәре.*
*Язып алу вакыты: ноябрь, 2022 ел.*

## Иманга килү — сабырлык

*Иң әүвәл кирәк нәрсә иман дигән,*
*Ахирәт эшләренә инан дигән.*
*Ходай кичер, дигән белән эш бетмәйдер,*
*Сәбәп эзләп иман шартын өйрән дигән.*
*Ходай кичер, дигән белән эш бетмәйдер,*
*Сәбәп эзләп иман шартын өйрән дигән.*

*Иң әүвәл кирәк нәрсә күңел дигән,*
*Күңеле бозык адәмнән дүңел дигән,*
*Бозыкка җир өстеннән асты артык*
*Булмаса күңел таза күмел, дигән.*
*Бозыкка җир өстеннән асты артык*
*Булмаса күңел таза күмел, дигән.*

*Иң әүвәл кирәк нәрсә акыл дигән,*
*Акылсызда тәүфыйк ягы такыр дигән,*
*Әз эшкә ачуланып динен бозар,*
*Иманын көферлеккә сатыр дигән.*
*Әз эшкә ачуланып динен бозар,*
*Иманын көферлеккә сатыр дигән.*

*Иң әүвәл кирәк нәрсә сабыр дигән,*
*Сабыр кеше морадын табыр дигән,*
*Һәр эштә сабырсызның төбе бурлык,*
*Сабырсызлык башка бәла салыр дигән.*
*Һәр эштә сабырсызның төбе бурлык,*
*Сабырсызлык башка бәла салыр дигән.*
*Сабырсызлык башка бәла салыр дигән.*

*Башкара: Нәзирова Фирдәүсә Кәбир кызы*
*(1950 елда туган).*
*Язып алынды: Саба районы, Алан-Елга авылы.*
*Язып алу вакыты: декабрь, 2022 ел.*

## Сыңар канат — иман нуры

*Ошбу айларда Рәсүл кыйммәте-*
*Булсакчы безләр аның өммәте.*
*Иман нурлары булсын безләрдә*
*Рәсүл шәфәгать күрсен безләргә.*

*Оҗмахны бизәр, колларны тезәр*
*Өммәтләр килә дип Рәсүл көтәр.*
*Тар каберләргә керер ятырбыз*
*Аллаһ каршына ничек барырбыз?*

*Кыямәт көне нинди авыр көй*
*Безләргә шәфкать Раббым үзең кыйл.*
*Ярлыкыйм дигән вәгъдәң бар синең,*
*Рәхмәтең салып Хәбибең диген.*

*Гөнаһы кыйлсак, гайбәт сөйләсәк-*
*Бер Ходай бездән тәмам бизәчәк*
*И кардәшләрем моны, аңлыйк без,*
*Дөньяда чакта белеп калыйк без.*

*Газраил килер, җаннарны алыр*
*Иманлы булсак рәхимен салыр.*
*Рәхимсез кылма иблис мәлгуньне*
*Игелекле кыл, син Мөнкир-Нәкирне*[2] *.*

*И Раббым, Аллам, рәхмәтең чиксез -*
*Синең рәхмәтең һич тә кимеми*

---

[2] Мөнкир-Нәкир — бу фәрештәләр мәет күмелү алдыннан сорау алалар.

*Ярлыкыйм дигән вәгъдәң бар синең*
*Рәхмәтең салып Хәбибең диген.*
*Ярлыкыйм дигән вәгъдәң бар синең*
*Рәхмәтең салып Хәбибең диген.*

*Башкара: Шәмсетдинова Вәсилә Гариповна (1956 елда туган).*
*Язып алынды: Саба районы, Тенеки авылы.*
*Язып алу вакыты: декабрь, 2022 ел.*

## Сабырлык

*Атамның бер гөле идем*
*Анамның былбылы идем,*
*Бу хәсрәткә гәҗиз булдым*
*Сабырлык бир үзем Аллаһ.*
*И, туганнар, беләсезме?*
*Минем хәлнең авырлыгын,*
*Пәйгамбәрләр сабыр иткән*
*Сабыр итеп әҗер алган.*
*Сабырлыкның сынакларын,*
*Китаплардан караганнар*
*Сабыр иткән кешеләрне*
*Шаһитлар дип санаганнар.*
*Сабыр итик, сабыр итик,*
*Сабыр колдан шайтан качар.*
*Сабыр коллар җәннәт ишеген*
*Үз куллары белән ачар.*
*Сабыр итик, сабыр итик,*
*Сабыр коллар сабыр итә.*
*Сабыр коллар сират күперен*
*Искән җилләр кебек үтә.*
*Сабырлыкны кайдан алыйм,*
*Сабыр итми кая барыйм,*
*Китап Коръәннәргә карыйм,*
*Сабырлык бир үзең Аллам.*
*Мөнәҗәтләр яза-яза*
*Каләм тоткан кулым тала*
*Мөнәҗәтем һич тә бетмәс*
*Кәгазь белән кара җитмәс*
*Йөрәгем дин-кайгы белмәс*

*Сабырлык бир, Раббым Аллаһ.*
*Мөнәҗәтем сезгә булсын*
*Дус-ишләрем дога кылсын,*
*Догаларыбыз кабул булсын*
*Рәхимең кыл, Раббым Аллаһ.*

*Башкара: Курмакаева Сания Якуб кызы*
*(1967 елда туган).*
*Язып алынды: Казан шәһәре.*
*Язып алу вакыты: ноябрь, 2022 ел.*

## Сабырлык

*Сынар канат, сынар канат*
*Каерылса чыкмый кабат,*
*Ташлап китте бер канатым*
*Сабырлыклар бирсен бер Хак.*
*Кыр казлары булды (м)инде*
*Серләшергә юк сердәшем,*
*Нишлим инде ялгыз башым*
*Сабырлык булсын юлдашым.*
*Сабыр коллар сабыр итә*
*Сабырның әҗәрен белеп,*
*Дәрәҗәләргә ирешә*
*Җәннәт әһелләре булып.*
*Сабыр итүнең савабын*
*Китаплардан караганнар,*
*Сабыр иткән бәндәләрне*
*Шаһитлар дип атаганнар.*
*Сабыр итик туганнарым*
*Сабыр колдан шайтан качар,*
*Сабыр коллар җәннәт ишеген*
*Үз куллары белән ачар.*
*Сабырлар җәннәткә керер*
*Аллаһның рәхмәтен күрер,*
*Сабырсызлар җәһәннәмгә*
*Сабыр бирсен Тәгал(ь) Алла.*
*Сабыр итмәгән бәндәнең*
*Гамәл дәфтәре буш булыр.*
*Бер Ходаем, сабыр әйлә*
*Сораганын кабул әйлә.*

*Фирдәүс җәннәтеңне*
*Барчабызга насыйп әйлә.*
*Фирдәүс җәннәтеңне*
*Барчабызга насыйп әйлә.*

*Башкара: Сиражиева Гөлүзә Абрар кызы*
*(1967 елда туган)*
*Язып алынды: Әтнә районы Олы Мәңгәр авылы.*
*Язып алу вакыты: ноябрь, 2022 ел.*

## Сабырлык

*Үлем хәле ачы икән*
*Йөрәк маен ашый икән,*
*Бу хәсрәткә сабыр итсәң*
*Ахирәттә яхшы икән.*
*Хәлем авыр кемгә сөйлим*
*Хәлләремнең авырлыгын,*
*И Ходаем, сабырлык бир*
*Пәйгамбәрләр сабырлыгын.*
*Эчем яна кеше күрми*
*Кеше хәлен кеше белми.*
*Кайгылардан кеше үлми*
*Сабырлык бир Тәгаләллам.*
*Укыйк «Әлхәм», әйтик «Салават»*
*Рәсүлулланың үзенә.*
*Кыямәт көне булганда*
*Карарбыз аның күзенә.*
*Рәсүлалла намаз укый*
*Яшел чапаннарын киеп,*
*Кыямәт көне булганда*
*Эзләрбез аны сөенеп.*
*Мөнәҗәтем бетәр микән*
*Язсам карам җитәр микән?*
*Җылап-җылап дога кылсам*
*Аллам кабул итәр микән?*
*И Ходаем, үзең сакла*
*Дошманнарның күзен капла,*
*Дошман артыннан җитмәсен*
*Аягыңны тизрәк атла.*

*Башкара: Нигъмәтҗанова Мәрвәр Мөбәрәкша кызы*
*(1954 елда туган)*
*Язып алынды: Әтнә районы Күлле-Киме авылы.*
*Язып алу вакыты: ноябрь, 2022 ел.*

## Ана һәм бала

*Утырдым күлнең читенә,*
*Карадым суның төбенә.*
*Су төпләрендә кара юл,*
*Язмышларны күрми чара юк.*
*Балаларым, бәгырьләрем,*
*Сезнең хакта гел уйланам*
*Йокы араларында төшемдә күреп уянам.*
*Су сип, балам, гөлләреңә,*
*Гөлләреңне корытма.*
*Туган илкәеңдә калган,*
*Әнкәеңне онытма.*
*Авыр булса дөньялары,*
*Урап алса сагышлары,*
*Бирешмә бу сынау гына*
*Аллаһ сөя сабырларны.*
*Рәхмәтеннән ташламасын,*
*Ярдәменнән калдырмасын,*
*Кайгы җилләре какмасын,*
*Бары тик Алла сакласын.*

*Башкара: Нигъмәтҗанова Мәрвәр Мөбәрәкша кызы*
*(1954 елда туган)*
*Язып алынды: Әтнә районы Күлле-Киме авылы.*
*Язып алу вакыты: ноябрь, 2022 ел.*

## Әнием бәгърем

*Әнием минем бәгыркәем,*
*Тар түгелме каберең,*
*Тар кабердә, салкын гүрдә*
*Әрнемиме бәгырең.*
*Төрле көннәрем булгандыр*
*Рәнҗемәдең микән миңа,*
*Оҗмах ишекләре ачык,*
*Булса иде әнием сиңа.*
*Ходайдан куркып яшәдең,*
*Рәнҗетмәдең бер кемне дә,*
*Тынычлап ят газиз әнием,*
*Нур балкысын кабереңдә.*
*Начарлыкка өйрәтмәдең,*
*Йомшак иде синең күңел,*
*Оҗмах кошы булгансыңдыр*
*Изге айларда күмелдең.*
*Уйлыймын да, җырлыймын да*
*Мөнәҗәт көйләрен көйләп,*
*Әнкәем янымда булсаң,*
*Бетмәс сүзем иде сөйләп.*
*Иртән торуга нихәл диеп,*
*Яннарыңа бара идем,*
*Теләкләр тели-тели*
*Дога кылып кала идең.*
*Очкан кошларда бара алмый,*
*Хәлләрең белешергә,*
*Ахирәттә насыйп булсын,*
*Әнием безгә күрешергә.*
*Кабер эчең тыныч булсын,*

*Тирә ягың нурлы булсын,*
*Минем әйткән мөнәҗәтем,*
*Әнием сиңа догам булсын.*
*Үзе әйтеп йөри торган*
*Мөнәҗәтләрең дә бар иде,*
*Сабыр төбе сары алтын,*
*Көйләп кенә йөрер иде.*
*И Ходаем, сорыйм синнән,*
*Гөнаһларым гафу әйлә,*
*Сигез җәннәт ишекләрен*
*Барчагызга насыйп әйлә.*
*Сигез җәннәт ишекләрен*
*Барчагызга насыйп әйлә.*

*Башкара: Хәйруллина Әлфия Барый кызы*
*(1951 елда туган)*
*Язып алынды: Буа районы, Түбән Наратбаш авылы*
*Язып алу вакыты: ноябрь, 2022 ел.*

## Ана

*Тугыз ай күтәреп йөрдем, тугач ак сөтемне бирдем*
*Бу ни гаҗәп, бу ни хәйран, баламның хәсрәтен күрдем.*
*Бишекләрдә тибрәткәндә, тала иде beләкләрем,*
*Сезләр тыныч булмасагыз, әрни минем йөрәкләрем.*
*Бала дигән асыл с(ч)ачак, ананың карынында ята*
*Баланың моңлы сагышы, ананың йөзен саргайта.*
*Бала дигән асыл агач, ананың карынында үсә*
*Баланың моңлы хәсрәте, ананың бәгырен кисә.*
*Бәгырь балам, газиз балам, ике күземә бер кара*
*Синең ялкынында янам, сабырлык бир Тәгала Аллам...*



*Башкара: Яхина Наилә Мәгъруф кызы*
*(1967 елда туган).*
*Язып алынды: Казан шәһәре.*
*Язып алу вакыты: ноябрь, 2022 ел.*

## Ятимнәр авазы

*Кырык бер дә ямьле җәйдә*
*Илгә дошман басып керде.*
*Безнең бәхетләр киселде,*
*Сабыйлык шунда өзелде*
*Сабыйлык шунда өзелде.*

*Без шул чорның балалары*
*Ялан аяк йөрдек кырда.*
*Алабута-кычытканнар,*
*Безгә ризык булды бар да,*
*Безгә ризык булды бар да.*

*Киим дисәң киеме юк,*
*Ашыйм дисәң юк ла ризык.*
*Күмәч пешерде аналар,*
*Черек бәрәңгене казып,*
*Черек бәрәңгене казып.*

*Әниләр көн буе кырда*
*Баса, чәчә, урак ура,*
*Кичен оек-бияләй бәйләп,*
*Юллый сугыш кырларына,*
*Юллый сугыш кырларына.*

*Авылымның биш йөз ирен*
*Сугыш уты ялмап алды.*
*Шуның өч йөздән артыгы*

Яу кырында ятып калды,
Яу кырында ятып калды.

Авыл тулы ятим бала
Хәсрәтеннән сулган ана.
Кичкә аяк-куллар шешә,
Әйтерсең лә таш багана.
Кичкә аяк-куллар шешә,
Әйтерсең лә таш багана.

Өстәлендә кара пичәт
Ирдән үлгән хәбәр килгән.
Иңдә ил, бала язмышы
Толның хәлен кемнәр белгән?
Толның хәлен кемнәр белгән?

Инде бар да артта калды
Яшибез нәкъ җәннәтләрдә.
И Ходаем, татулык бир
Падишаһларга, бәкләргә.
Падишаһларга, бәкләргә.

Бүтән сугыш булмасын дип,
Чакыру юллыйк биш кыйтгага
Ишетсеннәр шул авазны
Бар халкым һәм газиз Аллаһ.
Бар халкым һәм газиз Аллаһ.

Татулык бир бар халыкка
Төп хөкемдар —Раббым Аллаһ.

*Ля иляһе илляллаһу Мөхәммәд рәсүлуллаһ*
*Ля иляһе илляллаһу Мөхәммәдрәсүлуллаһ.*

*Башкаралар: Фәткуллина Руфия Мөбәрәкша кызы*
*(1947 елда туган),*
*Төхфәтуллова Зәүҗия Нурмөхәммәт кызы*
*(1940 елда туган).*
*Язып алынды: Буа районы, Яңа Тинчәле авылы.*
*Язып алу вакыты: ноябрь, 2022 ел.*

# Тормыш-көнкүреш, яшәеш мөнәҗәтләре

## Әйтәм, тыңлагыз…

*Бисмилләхи дип башлыймын*
*Тыңлар булсаң мөнәҗәтне.*
*Мөхәммәт өммәте өчен*
*Яраткан сигез җәннәтне.*
*Иманыңны үзең сакла,*
*Бозык сүзләр белән ватма,*
*Үзеңне җәһәннәмгә атма -*
*Бу дөньяга алданмагыз!*
*Алдамады ул кемнәрне*
*Җыйган малың барда калыр.*
*Гафыйль булма шул көннәрне,*
*Дуслар гайбәт сөйләмәгез.*
*Гайбәтченең эше харап,*
*Гайбәт сөйләгән(нәр) колларга*
*Эчермәсләр кәүсәр-шәраб.*
*Сәгадәтле булыйм дисәң,*
*Мәгърифәтне аңлыйм дисәң,*
*Бер Ходайга ярыйм дисәң,*
*Укы иртә кичен Коръән.*
*Бер Ходайга ярыйм дисәң.*
*Укы иртә кичен Коръән*
*Бер Ходайга ярыйм дисәң.*

*Башкара: Хаҗиева Гөлнур Заһретдин кызы*
*(1953 елда туган)*
*Язып алынды: Әтнә районы Мокшы авылы.*
*Язып алу вакыты: ноябрь, 2022 ел.*

## Картаябыз димик әле, мөнәҗәтләр көйлик әле

*Мөнәҗәтләр көйлик әле, тыңласагыз күңел салып,*
*Узган гомерләрне уйлап, утырам хәйранга калып.*
*Кая китте яшьлек елларым дим, яшел яфрак зәңгәр чәчәгем,*
*Беркем белми, күңелләр дә сизми, алгы көндә ниләр күрәчәген.*
*Авыр була уйлап утырсам да, узып бара инде гомерләр,*
*Авыр сүзне, авыр кайгыларны, күтәрә алмас инде күңелләр.*
*Ашыкмагыз картаерга, күңелләрегез тынмасын*
*Сагынып килдем ераклардан, карты вә яше тыңласын.*
*Сезләргә бүләкләр өчен, гөлләр чәчтем бакчабызга*
*Хәерле гомерләр бир син, бер Ходаем барчабызга*
*Картлык-шатлык түгел диеп, гел моңаеп йөрмик әле,*
*Барлык кайгыны онытып, бер елмаек, көлик әле*
*Картаябыз димик әле, мөнәҗәтләр көйлик әле.*

*Башкара: Садыкова Миңненур Закир кызы*
*(1952 елда туган).*
*Язып алынды: Саба районы, Шәмәрдән авылы.*
*Язып алу вакыты: ноябрь, 2022 ел*

## Бисмилла әйтеп башлыймын…

*Бисмилла әйтеп башлыймын*
*Тыңласагыз мөнәҗәтне.*
*Мөхәммәт өммәте өчен*
*Яралткан сигез җәннәтне.*

*Иманыңны үзең сакла*
*Бозык сүзләр белән ватма.*
*Бозык сүзләр белән ватып*
*Үзеңне җәһәннәмгә атма.*

*Бу дөньяга алданмыйк без*
*Алдамаган ул кемнәрне.*
*Җыйган маллар барда кала*
*Гафыйль булмыйк ул көннәрне.*

*Үзара гайбәт сөйләмик*
*Гайбәтченең эше харап.*
*Гайбәт сөйләгән кешегә*
*Эчерməсләр кәүсәр шәраб.*

*Сәгадәтле булыйм дисәң,*
*Мәгърифәтне алыйм дисәң,*
*Бер Аллаһка ярыйм дисәң,*
*Укы иртә-кичен Коръән.*

*Бу дөньяга алданабыз*
*Хәләл-харамны белмичә,*
*Аллаһның олы рәхмәтен*

*Белеп булмый шул үлмичә.*
*Уйла бәндәм үләсеңне*
*Кара җиргә керәсеңне,*
*Кара җир астына кергәч*
*Нинди җавап бирәсеңне.*

*Бакый иман белән үлсәк,*
*Фирдәүс җәннәткә керсәк,*
*Синең дидарыңны күрсәк,*
*Җитә Аллам, шуны бирсәң*
*Җитәдер Аллам, шуларны бирсәң.*
*Әмин! «Ля иляһы илляллаһу» Мөхәммәд рәсүлуллаһу.*

*Башкара: Равзетдинова Надия Вәли кызы*
*(1957 елда туган)*
*Язып алынды: Әтнә районы Олы Мәңгәр авылы.*
*Язып алу вакыты: ноябрь, 2022 ел.*

## Буш үткәрмә

*Мөнәҗәтләр язам сезгә*
*Кулларымнан бүләк итеп,*
*Әҗәл җитеп үлеп китсәм*
*Сез укырсыз мирас итеп.*

*Мөнәҗәтләр язып куям*
*Укысагыз искә алып.*
*Үткән гомерләрне уйлап*
*Торамын хәйран калып.*

*И туганнар, беләсезме*
*Гомер үтә сизәсезме?*
*Бу гомерләр үткәннән соң*
*Ниләр килер беләсезме?*

*Бу гомерләр үтәр-китәр*
*Әҗәл вакытлары җитәр.*
*Әҗәлләрнең җитүләре,*
*Гаклыбызны нәүмиз итәр.*

*И туганнар, беләсезме*
*Гомер үтә сизәсезме?*
*Бу гомерләр үткәннән соң*
*Ниләр килер беләсезме?*

*И дусларым, үлем килер*
*Аерып алыр җанны тәннән.*
*Беркемгә дә мөмкин түгел*

*Качып калу бу үлемнән.*
*Буш үткәрмә гомереңне*
*Якын дип бел үлемеңне,*
*Кичәләрдә зикер әйтеп*
*Тынычландыр күңелемне.*

*Уйлаек без үзебезне*
*Җилгә очырмыйк сүзебезне,*
*Аллаһ зикре белән*
*Ачаек дуслар сүзебезне.*
*Аллаһ зик(е)ре белән*
*Ачаек без күзебезне.*

*Башкара: Хаҗиева Гөлнур Заһретдин кызы*
*(1953 елда туган)*
*Язып алынды: Әтнә районы Мокшы авылы.*
*Язып алу вакыты: ноябрь, 2022 ел.*

## Теләкләрем

*Мөнәҗәт әйтәбез сезгә*
*Кардәшләрем, сез тыңлагыз.*
*Аллаһ хакы бигрәк бөек,*
*Берүк шуны онытмагыз.*
*Берүк шуны онытмагыз.*

*Йокыгыздан торган чакта*
*«Бисмилләһ» әйтеп торыгыз!*
*Шулай булса, гел уңышлы*
*Булыр гомер юлларыгыз.*
*Булыр гомер юлларыгыз.*

*Иңебездә фәрештәләр*
*Саклап йөрсен һәммәбезне.*
*Аллаһ үзе яраткан бит*
*Безнең Ислам динебезне.*
*Безнең Ислам динебезне.*

*Аллаһ үзе яраткан бит*
*Җирне, суны, күгебезне,*
*Бер Ходаем ярлыкасын*
*Балаларны, үзебезне.*
*Балаларны, үзебезне.*

*Бар тереклекне яраткан*
*Бер Ходаем, газиз Аллаһ.*
*Иманлы булып яшәгән*
*Әти-әни, әби-бабам.*
*Әти-әни, әби-бабам.*

Кул күтәреп дога кылыйк
Вафат булган якыннарга,
Ислам динен өйрәтик без
Үзебезнең балаларга.
Үзебезнең балаларга.

Саклый күрсен һәммәбезне
Аллаһның фәрештәләре,
Өебезне бизәп торсын
Коръән аять-сүрәләре.
Коръән аять-сүрәләре.

Йә Раббем, бәхет бир безгә,
Илләребез тыныч булсын,
Кан коюлар, җан кыюлар
Якын араларда тынсын!
Якын араларда тынсын!

Күпме газизләребезне
Ковид чире алып китте!
Канлы күз яшьләре түгеп
Яшәүләргә мәҗбүр итте.
Яшәүләргә мәҗбүр итте.

Бу афәтләрне туктатчы,
Йә кодрәтле Раббым Аллаһ
Ля иляһе илляллаһ, Мөхәммәд рәсүлуллаһ
Ля иляһе илляллаһ, Мөхәммәд рәсүлуллаһ.

*Башкаралар: Фәткуллина Руфия Мөбәрәкша кызы*
*(1947 елда туган),*
*Төхфәтуллова Зәүҗия Нурмөхәммәт кызы*
*(1940 елда туган).*
*Язып алынды: Буа районы, Яңа Тинчәле авылы.*
*Язып алу вакыты: ноябрь, 2022 ел.*

## Ярлыкауны сорыйм

*Мөнәҗәтләр әйтик әле*
*Бер Аллаһым разый булсын.*
*Барчабызга җәннәтләрдә*
*Булулары насыйп булсын.*
*Барчабызга җәннәтләрдә*
*Булулары насыйп булсын.*

*Йә башкаем ни уйлыйсың*
*Ни әйтерең бер Аллаһка.*
*Ля Иляһе илляллаһ*
*Зикер әйтик бер Аллаһка*
*Зикер әйтик бер Аллаһка.*



*Йә күзләрем ни күрдегез*
*Ни әйтерсең бер Аллаһка?*
*Ля Иляһе илляллаһ*
*Зикер әйтик бер Аллаһка*
*Зикер әйтик бер Аллаһка.*

*Йә авызым ни сөйләдең*
*Ни әйтерсең бер Аллаһка?*
*Ля Иляһе илляллаһ*
*Зикер әйтик бер Аллаһка*
*Зикер әйтик бер Аллаһка.*

*Колакларым ни ишеттең*
*Ни әйтерсең бер Аллаһка?*
*Ля Иляһе илляллаһ*

*Зикер әйтик бер Аллаһка*
*Зикер әйтик бер Аллаһка.*

*Йә колларым ни эшләдегез*
*Ни әйтерсез бер Аллаһка?*
*Ля Иляһе илляллаһ*
*Зикер әйтик бер Аллаһка.*

*Аякларым кая бардың*
*Ни диярсез бер Аллаһка?*
*Ля Иляһе илляллаһ*
*Зикер әйтик Бер Аллаһка.*

*Йә карыным ни тукландың,*
*Ни диярсең бер Аллаһка?*
*Ля Иляһе илляллаһ*
*Зикер әйтик бер Аллаһка*
*Зикер әйтик бер Аллаһка.*

*Башкаралар: Фәткуллина Руфия Мөбәрәкша кызы*
*(1947 елда туган).*
*Язып алынды: Буа районы, Яңа Тинчәле авылы.*
*Язып алу вакыты: ноябрь, 2022 ел.*

## Бу мөбарәк җомга көн

*И мөселман кыл гыйбадәт,*
*Бу мөбәрәк айларда,*
*Укы намаз илә Коръән*
*Бу мөбәрәк җомга көн.*
*Зикер илә, әйт «Салават»,*
*Бу Мөхәммәд рухына,*
*Ничә мең савап язылыр*
*Бу мөбәрәк җомга көн.*
*Сәдака әйләсәң әгәр,*
*Һәр нәрсә дин бер микъдар.*
*Ничә мең савап язылыр,*
*Бу мөбәрәк җомга көн.*
*Әрвахларыбыз җомга көнне,*
*Бәйрәм итеп белерләр,*
*Гаиләләре ишегенә*
*Бу кичәдә килерләр.*
*Әрвахларыбыз килерләр,*
*Сәдака, дога теләп*
*Без аларны шат итәек,*
*Бу мөбәрәк җомга көн.*
*Иманлы һәм юмартларның*
*Шат булыр әрвахлары,*
*Кабул булыр догалары,*
*Бу мөбәрәк җомга көн.*
*Салаватулла галәйкә,*
*Йә сәедел мөрсәлин,*

*Җөмләбезгә рәхмәт әйлә,*
*Йә иляһым гәләмин.*
*Җөмләбезгә рәхмәт әйлә,*
*Йә иляһым гәләмин.*

*Башкара: Хайруллина Әлфия Барый кызы (1951 елда туган).*
*Язып алынды: Буа районы, Түбән Наратбаш авылы.*
*Язып алу вакыты: ноябрь, 2022 ел.*

## СҮЗЛЕК, ИСКӘРМӘЛӘР[1]

1. *Адәм* (борынгы яһүд. кеше) — күп кенә халыкларның изге китапларында (Тәүрат, Коръән) һәм мифологиясендә — беренче кеше, кешелекнең нәсел атасы. Коръәндә бәян ителгәнчә, Аллаһ Адәмне туфрактан һәм «җан өрелгән» балчыктан үзенең Җирдәге «урынбасары» (хәлифәсе) сыйфатында, барлык фәрештәләрдән өстен итеп яралта һәм аларга Адәмгә буйсынырга боера.

2. *Аллаһ* (гар.) — ислам динендә иң югары илаһи Зат, аның 99 исеменең иң беренчесе. Исламда Аллаһ бер һәм бердәнбер илаһи көч, дөньяны яралтучы. Кыямәт көнендә хөкемдар, кешеләр арасына Мөхәммәд пәйгамберне үзеннән илче итеп җибәрүче.



3. *Аты сөндүс* — аты ягъни исеме, ә «сөндүс» сүзе ефәк дип тәрҗемә ителә.

4. *Аять* (гар.) — Коръән сүрәләренең иң кечкенә бүлеш берәмлеге — мәгънәви яктан мөстәкыйль бербөтен тәшкил иткән (аерым догалар булып укыла, кабер ташларында һ. б. да языла торган) өзекләр, җөмләләр.

5. *Әҗәл* (гар.) — үлем, үлем вакыты.

6. *Әзәл* (гар.) — башлану вакыты булмаган борынгы заман, мәңгелек.

7. *Әл-Фирак* (гар.) — аерылу, аерылышу.

8. *Әләм* (гар.) — байрак.

9. *Әлхәм* (гар.) — Коръәннең беренче сүрәсе, Алланы мактау, аңа дан җырлау сүрәсе. Фатиха сүрәсенең беренче сүзеннән кыскартып ясалган.

---

[1] Сүзлек, искәрмәләр «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге» (1979,1981), «Татар мифологиясе: энциклопедик сүзлек» (2009), «Электронный фонд словарей» (https://suzlek.antat.ru/) таянып төзелде.

10. *Әрвах* (гар.) — мәрхүм кешенең рухы.

11. *Әһел* (гар., җәннәт әһеле) — бу очракта җәннәтнең бер әгъзасы, кешесе, вәкиле.

12. *Бер Хак* (гар.) - Алла, Аллаһы Тәгалә, Ходай.

13. *Борак* (Рәсүлуллаһ боераклары, Пырак) — Мигъраҗ кичәсендә Мөхәммәт пәйгамбәр өстенә атланып Мәккәдән Иерусалимга күчкән җан иясе. Җәбраил фәрештә тарафыннан Рәсүлуллага Мигъраҗ кичәсендә, аның күз ачып йомганчы Күккә ашуы һәм кире әйләнеп кайтуы өчен, Аллаһы Тәгалә тарафыннан махсус бирелгән могҗизалы хайван. Яшен тизлегендә чаба, оча торган, ялтырап үткән ат вазифасын башкаручы мифологик хайван.

14. *Ваҗип* (вәҗеп, вәҗеп) — бурыч.

15. *Гаҗиз булу* (фар.) —интегү, аптырап бетү, ни эшләргә дә белмәү.

16. *Газраил* (гар., Җәбраил) — җан алучы фәрештә. Ислам тәгълиматы буенча Аллаһы Тәгаләгә якын дүрт фәрештәнең берсе, үлем фәрештәсе.

17. *Гаклыбыз* (гар. гакыл, акыл) — фикерләү, фикер йөртү.

18. *Гамәл дәфтәре* — ике фәрештә тарафыннан кешенең һәр яхшы һәм яман эшләре (гамәлләре) теркәлә торган дәфтәр.

19. *Гарип* (гар.) — 1) физик җитешсезлеге булган кеше, зәгыйфь. 2) Туган иленнән аерылып, читтә яшәүче, читтән килгән кеше, юлчы, мосафир.

20. *Гүр* (фар.) — кабер.

21. *Гыйбадәт кылу, гыйбадәт* (гар.) — үзең инанган Аллага мөрәҗәгать итү, аңа табыну, ялвару, аны олылау белән бәйле дини гамәл.

22. *Гыйрфан* (гар.) — аң-белем, тәрбия, тәрбиялелек.

23. *Дәхи* — тагын бер мәртәбә, яңадан.

24. *Дидар* — зат.

25. *Җәннәт* — (гар.) Аллаһы Тәгалә тарафыннан мөэмин-мөселманнарга вәгъдә ителгән изге рәхәтлек, мәңгелек бәхет урыны. Коръән аятьләренә күз салсак, анда җәннәтнең берничә төре китерелә. Аның шулкадәр матур төгәл тасвирлануы төрки-татар халыклары иҗатының мөнәҗәт һәм бәет, җыр, мәкаль һәм әйтемнәрендә киң чагылыш таба.

26. *Җәһат итү* (җәһәт итү) — тизләтү, ашыктыру.

27. *Җөмләбез* — барчабыз, барыбыз.

28. *Иляһ* (гар., Илаһ) — Алла, Ходай, Тәңре.

29. *Иман* (Бакый иман) — (гар.) 1) Аллага, пәйгамбәрләргә, диннең төп нигезләренә ышану һәм шәригать таләпләрен тулысынча төгәл үтәү. 2) Мөселман булуга дәлил итеп укыла торган дога сүзләре.

30. *Кабык* — мәетне зиратка алып бару өчен ышкылмаган агач такталардан ясалган махсус носилка.

31. *Кара пичәт* — «кара кайгы», «өчпочмаклы хатта үлем хәбәре».

32. *Катыйлганчы* — «җан кыелганчы».

33. *Кәгъбә* — Мәккә шәһәрендәге сөнни мөселманнар өчен күктән иңгән, изге дип санаган кара таш куелган һәм хаҗга баруның төп максаты булган мәчет.

34. *Кәүсәр* — оҗмах чишмәсе суы, оҗмахтагы татлы су. Еш кына мөнәҗәтләрдә кәүсәр елга, кәүсәр шәраб эпитетлары кабатланып килә.

35. *Кол* — бу очракта Аллага буйсынган кеше, бәндә.

36. *Кыямәт* — бу дөньяның соңгы көне, мөэмин-мөселманнарны сынау көне. Ислам дине тәгълиматы, Ахырзаман

җиткәч, Исрафил пәйгамбәр сурына өрә һәм шул тавыштан үлгәннәрнең барысы да тереләләр. Алар Аллаһы Тәгалә каршына килеп, аның хөкеменә тартылалар. Шушы көн Кыямәт көне дип атала.

37. *Ләхет* — мәет кую өчен кабер төбенең бер як кырыеннан эчкә таба чокып ясалган урын, уем.

38. *Мәгърибъ* (мәгърип) — Көнбатыш.

39. *Мәзһәб* — гыйлемдә, фәлсәфәдә, бу дөньяга караштa тоткан юл, юнәлеш.

40. *Мәләк* — фәрештә.

41. *Мәшрикъ* — Көнчыгыш.

42. *Мизан* — үлчәү, бизмән.

43. *Мөнкир-Нәкир* — бу фәрештәләр мәет күмелү алдыннан аңардан сорау алалар. Бу фәрештәләр риваятьләрдә еш телгә алына.

44. *Өммәт* (гар.) — 1) Алладан җибәрелгән әмерне яшәештә кабул иткән мөселман халыклары; 2) Мөселман җәмгыятенә караганлык; 3) Халык, милләт.

45. *Рамазан (Рамадан)* — Айның Җир тирәли хәрәкәтенә карап (һиҗри белән) ел исәпләү календаренда тугызынчы ай; изге айлардан саналган ураза ае.

46. *Раббы (Раббе)* — Алла, Ходай, Тәңре.

47. *Рәсүл* (гар.) - Пәйгамбәр, Алланың җирдәге илчесе.

48. *Рауза* — гөл бакчасы.

49. *Руза* (фар.) — ураза.

50. *Савап, савап язылу* (гар.) — нинди дә булса игелекле эш-гамәлләр өчен Аллаһ тарафыннан киләчәк әҗер.

51. *Салават әйтү* — 1) Мөхәммәд пәйгамбәргә хөрмәт белдерү өчен укыла торган дога. 2) Мактап-хуплап яки хәерле юл, уңыш теләп дога уку.

52. *Сәгадәтле* — бәхетле.

53. *Сәдака, садака* — дини йолаларны үтәү йөзеннән мәчеткә, гарипләргә бирелә торган хәер.

54. *Сәдәф* (гар.) — бизәнү әйберләре, төймәләр һ.б.ш. ясауга китә торган материал, перламутр (гадәттә, бака кабыгының матур төс биреп тора торган эчке катламы).

55. *Сәҗдә кылу* — намазда тезләнеп һәм учларга таянып, маңгай белән җиргә тию.

56. *Сөаль* (гар.) — сорау.

57. *Тарыйкать* —дөреслек, туры гамәл.

58. *Тәүхид* (гар.) — дини Берилаһлык, монотеизм.

59. *Хава* — Алла тарафыннан ире Адәмнең кабыргасыннан яратылган иң беренче хатын-кыз, барлык кешеләрнең нәсел анасы.



60. *Хәер-дога* — яхшы теләк, яхшы дога.

61. *Чук сәлам* — күп сәлам.

62. *Шайтан* (гар.) — 1) Фәрештәләрнең җитәкчесе була торып Аллаһыга каршы баш күтәргәне өчен, Аллаһ тарафыннан куылган барлык; Иблис. Шайтан — Адәм белән Хаваны җәннәттән чыгарган явыз зат. 2) Шул барлыкның дәвамы буларак адәм балаларында булган, аларны котыртып, туры юлдан яздырып, аздырып торган явыз көч.

63. *Шәригать* (гар.) — мөселманнарның Коръәндә билгеләнгән әдәп, хокук, тәртип кагыйдәләре җыелмасы һәм шул кагыйдәләрне Аллаһ кушканча үтәү тәртибе аңлатмалары.

64. *Шәфәгать* (гар.) — берәр гаепнең гафу ителүе яки берәр теләкнең үтәлүе өчен арадашчылык.

# Мөнәҗәтләр – җан авазы